«Россиядә ислам фикере:
яңарыш һәм яңача карашлар» сериясеннән

*Муса Җаруллаһ Бигиев мирасы*

МЕДИНА
2007



**Муса Җаруллаһ Бигиев**
**1875–1949**

Үзәкләштерелгән дини оешма
РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ

Югары белем бирү оешмасы
МӘСКӘҮ ИСЛАМ ИНСТИТУТЫ

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫ»
югары һөнәри белем бирү федераль бюджет оешмасының
ИСЛАМ ФӘННИ-ТИКШЕРҮ ҮЗӘГЕ

Муса Җаруллаһ Бигиев

# МӘЕТ ЯНДЫРУ МӘСЬӘЛӘСЕ ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНДА

*Муса Җаруллаһ Бигиевның 150 еллыгына (1875–1949)*

МЕДИНА

Мәскәү, 2024

УДК 28
ББК 86.38-6
Б 59

*Китап Ислам мәдәниятен, фәнен һәм мәгарифен торгызу фондының матди катнашы белән әзерләнеп басылды*

**Рецензентлар:**
*Ислам Зарипов,* тарих фән. канд.;
*Рамиль Адыгамов,* тарих фән. канд.

**Сериянең җаваплы мөхәррирләре:**
*А. Г. Хәйретдинов,* фәлсәфи фән. канд., доцент; Татарстан Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани ис. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, Мәскәү ислам институтының Муса Бигиев ис. үзәк җитәкчесе;
*Р. В. Ислямов,* Мәскәү ислам институтының фәнни эшләр буенча проректоры.

**Серияне матбугатка әзерләү өчен җаваплы мөхәррирләр:**
*Г. Ю. Хабибуллина,* педагогия фән. канд., Мәскәү ислам институты ислам белем бирү системасының фәнни үсеш үзәге җитәкчесе;
*Р. И. Баишев,* Мәскәү ислам институтының илаһийәт бүлеге деканы.

**Серияне бастырып чыгару өчен җаваплы:**
*С. М. Абубакаров,* СПбГУ магистры, Мәскәү ислам институты аспиранты, ДУМ РФ рәисенең икенчел ярдәмчесе.

**Китапны бастырып чыгару өчен җаваплы:**
*И. А. Нуриманов,* РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең ярдәмчесе, “Медина” Нәшрият йортының ген. дир.

**«Россиядә ислам фикере: яңарыш һәм яңача карашлар” сериясенең баш мөхәррире:**
*Д. В. Мухетдинов,* илаһийәт докторы, сәяси фән. канд., Санкт-Петербург дәүләт университеты профессоры.

**Сериянең редакция советы:**
Бабаджанов Б. М., Гайнутдин Р. И., Гасымов К. Т., Гёрмез М., Кириллина С. А., Кныш А. Д., Муминов А. К., Мухетдинов Д. В., Наумкин В. В., Пиотровский М. Б., Попова И. Ф., Тауфик И. К., Фролов Д. В., Хабутдинов А. Ю., Хайретдинов Д. З., Юзеев А. Н.

**Сериянең редакция коллегиясе:**
Абубакаров С. М., Адыгамов Р. К., Алексеев И. Л., Баишев Р. И., Бородай С. Ю., Гатин Р. Н., Гибадуллин И. Р., Гимадеев И. Ф., Зарипов И. А., Ибрагимов Р. Р., Измайлов Р. Р., Ислямов Р. В., Канлыдере А., Казаков С. В., Макаров Д. В., Мараш И., Нуриманов И. А., Салахов А. М., Фархшатов М. Н., Хабибуллин Т. Х., Хабибуллина Г. Ю., Хайрутдинов А. Г., Шихалиев Ш. Ш.

***Бигиев, Муса***

Мәет яндыру мәсьәләсе Дәүләт думасында / Мәскәү исл. ин-ты; баш мөхәррир Д. В. Мухетдинов редакциясендә; госманлы татар теленнән тәрҗемә: А. Г. Хәйретдинов. — Серия: «Россиядә ислам фикере: яңарыш һәм яңача карашлар» (Муса Җаруллаһ Бигиев мирасы). — М.: «“Медина” Нәшрият йорты», 2024. 72 б.

ISBN 978-5-9756-0248-0

Алдыбызда Муса Бигиевның Дәүләт думасы мөселман фракциясе әгъзалары үтенүе буенча язылган доклады. 1913 нче елның 27 нче июнендә Россия Эчке эшләр министрлыгы дүртенче чакырылыш Дәүләт думасына, җеназа үткәрү белән бәйле кыенлыкларны һәм куркынычларны атап күрсәтеп, мәетләрне яндырырга тәкъдим ителгән закон проектын җибәрә. М. Бигиев, Коръән кәрим аятьләре нигезендә аңлатып биреп, вафат булганнан соң кешенең дини-әхлакый кануннар буенча җирләнергә хокукы барлыгын исбатлый.

© ООО «“Медина” Нәшрият йорты», 2024
© А. Г. Хәйретдинов, тәрҗемә, 2024
© Л. С. Хасьянова, портретлар, 2017, 2021

# Эчтәлек

7 Кереш сүз

15 Мәет яндыру мәсьәләсе Дәүләт думасында

37 Төшенчәләрнең кыскача сүзлеге

70 Факсимиле



**Муса Бигиев**
**(1875–1949)**

# Кереш сүз

*«Терек чакта җир йөзендә тору кешенең изге хокукыдыр. Бәгъде-л-мәүт, җир эчендә җәсәднең урын алуы да, кешенең мөкаддәс хакы булып тора. Йортларның кешеләргә мөнәсәбәте нинди булса, каберләрнең дә мәетләргә мөнәсәбәте шундыйдыр»*[1].

بسم الله الرحمن الرحيم

**Сәлам сезгә, кадерле укучым!**

Сез “Муса Бигиев мирасы”ннан “Россиядә ислам фикере: яңарыш һәм яңача карашлар” сериясенә кергән китапны кулыгызга алдыгыз. Бу хезмәт — мәшһүр ислам дине галиме Муса Бигиевның (1875–1949) “Мәет яндыру мәсьәләсе Дәүләт думасында” дип аталган күренекле дини-хокукый әсәренең госманлы татар теленнән хәзерге татар теленә тәрҗемәсе[2].

Үзенең гомере буе ул ислам хокукы (фикъһы) мәсьәләләрен тирәнтен итеп өйрәнде, Русия мөселманнары арасында һәм бөтен дөнья мөселманнары даирәсендә үсеш алган алдынгы фикер

[1] Карагыз: әлеге нәшер ителгән басма, 20 нче б.

[2] *Бигиев М.* Мәет яндыру мәсьәләсе (Дәүләт думасында). Санкт-Петербург: Типография М.-А. Максутова, 1914. 16 б.; *Бигиев М.* Проблема кремации, озвученная в Государственной думе / под общ. ред. Д. В. Мухетдинова; пер. с тат.-осман. и примеч. А. Г. Хайрутдинова. Серия: «Исламская мысль в России: возрождение и переосмысление». М.: ИД «Медина», 2022. 64 с.

алышуларны куәтләп, исламда модернизм карашларын үстерде. Ул җәдитчелек, ягъни «яңарыш»[3] хәрәкәтенең иң күренекле вәкилләреннән берсе булды. Җәдитчелекнең төп омтылышы — Коръән кушканнарның асылына туры килмәгән, ләкин ислам җәмгыятендә һәм ислам өстенлек иткән илләрдә теге яки бу сәбәп белән урнашып калган, искергән нормаларны яңадан карау иде.

Китап татар телендә беренче тапкыр дөнья күрде.

«Мәетләрне яндыру мәсьәләсе (Дәүләт думасында)» әсәренең исемендә үк Муса Бигиев хезмәтләрендә Россия мөселман җәмгыятенең иҗтимагый-дини тормышы белән бәйле рәвештә кузгатылган күп темаларның берсе чагылыш тапкан. 1913 нче елда Дәүләт думасына кертелгән кремация турындагы закон проекты, парламентның мөселман фракциясе алдына, бу мәсьәләне ислам күзлегеннән карап ничек аңларга, дигән сорауны куя. Моның өчен алар, яңа заман куйган мәсьәләләргә бер тапкыр да битараф кала белмәүче, танылган дин галиме Муса Бигиевка мөрәҗәгать итәләр.

Авторның бу мәсьәләгә юнәлтелгән игътибары, һичшиксез, аның җәдитчелекнең яңарту юнәлеше белән тыгыз бәйләнгән фикер алышуларда күңел биреп катнашуын раслый. Тексттан күренгәнчә, Муса Бигиев, Коръән сүзенең байлыгына таянып, мәсьәләне ачык аңлатып бирә. Ул, Коръән күрсәтмәләренең асыл нигезе булган рухи һәм гамәли бердәмлеккә мөрәҗәгать итеп, тормыш өчен бу иң акыллы юл булуын исбатлый.

Коръән һәм шәригать күрсәтмәләрен тормышка ашыру өчен һәм шуның белән җәмгыятьнең үсешенә ирешү өчен, бу күрсәтмәләрне мөстәкыйль рәвештә, нигезле итеп аңларга һәм аңлатырга омтылыш — ислам модернизмы дип аталган юнәлеш галимнәренең төп максаты

[3] Җәдитчелек хәрәкәте турында тулырак итеп, карагыз: *Юзеев А. Н.* Просветительская мысль татарского народа. Казань: Татарское книжное издательство, 2014. С. 307–384; *Хабутдинов А. Ю., Мухетдинов Д. В.* Российские мусульмане-татары: от общины к нации (конец XVIII — начало XX в.): Учебное пособие. Н. Новгород: Издательский дом «Медина», 2007. 132 с.; *Мухетдинов Д. В., Юзеев А. Н.* Основные направления развития философской мысли татарского народа (X–XX вв.). Н. Новгород: Издательский дом «Медина», 2009. 208 с.; *Мухетдинов Д. В.* История ислама в России: учебное пособие / под общ. ред. В. В. Трепавлова. М.: ИД «Медина», 2019. С. 152–178.

булып тора. Бу юнәлеш дәвамчылары арасында без Ф. Рахманны (1919–1988) атый алабыз. Ф. Рахман үз әсәрләрендә — Әбу Исхак Әш-Шатыбиның (1388 ваф.) «Макасыд әш-шәрига» хезмәтенә нигезләнеп, хосусыйдан — гомумигә, аннан гомумидән хосусыйга эзлекле хәрәкәт итә барган икеләтә көчеш теориясен үстерә. Тормышны югары канун нигезендә төзү өчен, гомуми принципларны, ягъни, Аллаһ Тәгалә боерганнарны, акыл белән аңлап, шуңа охшаш юл белән хосусый карар чыгаруның әһәмияте зур[4]. Заман куйган һәр мәсьәләне чишү өчен электән килгән гадәтләргә сукырларча ияру дөреслектән ерак тора, чөнки бу — кайчандыр кешеләр уйлап тапкан, Коръән кушканга да, акылга да каршы килә торган уйдырмалар булуы мөмкин. Муса Бигиев үзенең хезмәтләрендә дингә яңалыклар кертергә өндәмәгән, ниндидер тар сәяси программа тарафдары да булмаган, әмма илдә күтәрелгән сорауларны исәпкә алып, Коръәннең бетмәс-төкәнмәс хакыйкате нигезендә, иҗтимагый оешмаларны яңарту юлларын табарга һәм күрсәтергә тырышкан.

Ислам галимнәре хезмәтләрендә үлем һәм ислам гадәте буенча җирләү мәсьәләләренә кагылышлы тема, кеше тәне һәм җанының табигате турындагы тәгълимат белән дә, җирдәге яшәеш һәм киләчәк тормыш турындагы мәсьәләләр белән дә турыдан-туры бәйле. Әбу Хәмид әл-Газали (1058–1111), кеше тәне материядән барлыкка китерелгән һәм ул барлыкка китерелгән табигатьнең бер өлеше дип аңлата. Ул үсә, картая һәм үлемгә дучар була, ә җан кеше тәне белән бергә үлми, җан — рухи дөньяның үлемсез өлеше. Шулай итеп, кеше өчен үлемнән соңгы тормыш башлана. Бу соңгы тормышта җанның газаплары — нәфес омтылышлары бетеп җитмәгәнлек белән бәйле, ә рухи газаплар матди байлыкларга өмет өзмәгәннәргә яный. Шуңа күрә үлем — дөнья тормышын тәмамлауның мөһим вакыйгасы, аңа тиешле игътибар бирергә кирәк. «Бу дөнья тормышы күпмедер дәрәҗәдә төшкә охшаган, ә чын тормыш башка дөньяда башланачак.

[4] *Мухетдинов Д. В.* Исламское обновленческое движение конца XX — начала XXI в.: идеи и перспективы: дис. д-ра теологии. СПб., 2019. С. 59–62; *Мухетдинов Д. В.* Гуманистиеская коранистика Фазлура Рахмана // Ислам в современном мире. 2020. Т. 16. № 2. С. 57–68.

Дингә инанучылар бу дөньяны — күз алдыбыздагы матди дөньяны — кире какмыйлар, ләкин алар беркайчан да аңа артыгын кызыгып, аның тоткыны, әсире булып китәргә тиеш түгелләр. Мөэминнәр вакытлыча дөнья рәхәтлекләре белән мавыкмыйча, үзләренең рухи вазыйфаларын онытмыйча, җан сафлыгын кайгыртып яшәргә тиешләр. Мәңгелек тормышта чын бәхеткә ирешү өчен, иманлы кешенең аңына фидакарьлек хисе һәм дөнья рәхәтлекләреннән ваз кичү хас»[5].

Мәрхүмнең җәсәденә карата тиешле гамәлләрне үтәү һәм аны кабергә иңдерү йоласын башкару тәртибенә караган шәригать хөкемнәре кешенең җанына, һәм, Аллаһ әмере белән, аның өчен дөньялыкта җанны саклагыч йорт булып хезмәт иткән гәүдәсенә хөрмәт күрсәтү йөзеннән, динебездә фарыз. Бу йолалар ахыргы сәгате җиткән кешене үлемгә әзерләү, үлгәннән соң мәетнең җәсәден юу, кәфенләү, җеназа намазы укылу, күмү урынын хәстәрләү, каберенә кадәр җәмәгать белән озата бару, кабердә ләхет эченә урнаштырып дәфен итү, күмелгәннән соң укыла торган догалар һ. б. ны үз эченә ала. Мәрхүмнең гәүдәсен яндыру турында мөселманнарга башка халыкларның гадәтләре аша билгеле, ләкин йола буенча бу — ярамый торган, бөтенләй чит бер нәрсә.

Тәкъдим ителгән китапта сүз кешенең үз белдеге белән, илаһи табигатькә каршы килеп кылган эшләре турындагы мәсьәләләр белән башланып китә. Муса Бигиев аңлатуынча, табигать юнәлткәннәргә игътибарлы булуны Коръән кәрим яклый, чөнки табигать үзе дә илаһи максат белән иҗат ителгәнлектән, явыз эшләргә этәрә алмый, табигать һәрчак дөрес юлга таба алып бара. Дөрес юлны табу өчен, кеше табигатьне тыңларга һәм Коръәндә теге яки бу мәсьәлә буенча ни әйтелгәнен яхшы белергә тиеш — табигатьнең күрсәтмәләрен дөрес аңласаң, алар Коръән әмерләренә каршы килергә тиеш түгелләр. Мондый мәсьәләләргә мәетләрнең җәсәденә карата мөнәсәбәт тә керә.

[5] *Гайнутдин Р.* Ислам: вероучение, поклонение, нравственность, закон. М: ИД «Медина», 2020. С. 89.

Муса Бигиев, кешеләргә мәетләрне җиргә күмәргә кушыла, дип, Коръәннән ике төрле аңлау мөмкинлеге калдырмый торган ышанычлы дәлилләр китерә. Алга таба бу рухи күзлектән дә, матди яктан да нигезләп аңлатыла. Аллаһ яралткан кеше үзе дә, җәсәде дә мөхтәрәм, исән чагында да, үлгәннән соң да аңа ихтирам булырга тиеш. Шәригать кушканча дөрес итеп җирләү — бу ихтирамның иң ачык күренеше, исәннәрнең дини вазифасы булып тора. Бу бурыч кешеләргә әйләнә-тирә мохитне зарарлы нәрсәләрдән саклау өчен, зыянлы матдәләр белән һава агуланмасын өчен йөкләнелгән. Шул рәвешчә, кеше җәсәден тәшкил иткән матдә яңадан җиргә кайтарыла. Бу сәбәпләр аркасында, кешеләрне җирләү гадәте ислам диненә туры килү белән беррәттән, матди дөнья өчен дә файдалы. Мәдәниятләре алга киткән илләрдә, дип әйтә Бигиев, гадәт буенча мәетләрне җиргә күмү кабул ителгәнлектән, каберлекләрне төзекләндереп карап тору өчен махсус кагыйдәләр дә расланган.

Муса Бигиевның бу мәсьәләгә карашының үзенчәлеге шунда — ул кайбер халыкларда мәетләрне утта яндыру гадәтен дә таный. Исламга туры килмәсә дә, башка милләтләрнең дини әдәпләренә каршы чыгудан, аларны тәнкыйтьләүдән ерак тора. Ул мәет яндыру кебек гадәтләрнең уңай якларын да күрсәтә. Шулай да, бу мәсьәләдә Муса Бигиев ислам шәригатендәге әдәпләрнең югарылыгын билгели; каберлекләрне тәртипкә китерү һәм җирләү урыннарын кабат куллану турында да киң аңлатмалар биреп, боларның табигатькә һәм җәмгыять ихтыяҗларына да туры килүен күрсәтә.

М. Бигиев, мәетләрне яндыру шәригать кушканнарга да, йолаларыбызга да туры килмәвен билгеләп, мөселманнарга үлгәннәрне җирләү тиешлеге күрсәтелгәнен аңлатып бирә, әмма шулай да мәетләрне яндыру турындагы канун проектына каршы бер сүз дә әйтми, чөнки, аның сүзләре белән, “мәетнең дине каршы килмәсә, тере чагында ул кешенең ризалык биргән булуы расланса, ул чакта мәетнең җәсәде көлгә әйләндерелә”[6]. Әгәр дә инде кешенең дине мәетне яндырырга рөхсәт итмәсә, хәтта

[6] Карагыз: әлеге басма, 25 б.

үзенең җәсәден үлгәннән соң яндыру хакында бер кеше исән чагында васыять калдырган булса да, аның андый васыяте гамәлгә ашырылмый. Хәзерге заманда эпидемия таралу куркынычы, яңа төр йогышлы авырулар барлыкка килү мәетләрне яндыру мәсьәләләренә кабаттан игътибарны юнәлтә. Шул ук вакытта, хәзер шунысы да ачыкланды: эшләп торучы крематорийләр саны арта бару сәбәпле, сәнагать дезодорантлары да көннән-көн күбрәк кулланыла бара, бу, үз чиратында, әйләнә-тирә мохитне боза[7]. Шулай итеп, Муса Бигиев, җәмгыять алдында торган мәсьәләләрне ачыклаганда, хөкүмәт югарылыгыннан торып, кешеләргә тыелган нәрсәләрне мәҗбүри рәвештә тагарга омтылмый, кремация практикасын дине мәетләрне яндырырга рөхсәт иткән һәм яндыруны изге санаганнар өчен рөхсәт ителә, дип аңлата.

Шул ук вакытта ул, шәригать күрсәтмәләреннән баш тартмыйча, мөселманнарга үлгәннәрнең мәетләрен шәригать кушканча күмү кирәклеген искәртә. Шуның белән ул социаль һәм дини мәсьәләләрне чишүдә үзенең юридик тәҗрибәсенә таяна. Шул рәвешчә, М. Бигиев, Дәүләт думасының законнар чыгару эшчәнлеге даирәсендә фикер алышуларда катнашып, иң югары дәүләт дәрәҗәсендә, диннәр арасында яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыруга үз өлешен кертә.

Муса Бигиев әсәрләрендә чагылган Русия мөселман теологик фикерен яңарту традициясе, безнең гасырда да мөселманнарның үз тормышындагы иҗтимагый мәсьәләләрне чишүләрендә дә, илебезнең барлык халыкларына кагылышлы проблемаларны хәл итүдә дә аңлы гражданнар буларак катнашуларына хезмәт итәр дип ышанабыз.

Күренекле галимнәребезнең тәҗрибәләре белән танышу безгә аларның шушы тәҗрибәсен — бер-бере белән үзара тыгыз

---

[7] *Люббе Г.* В ногу со временем. Сокращенное пребывание в настоящем. М.: Издательский дом Высшей школы экономики, 2016. С. 45–46.

бәйләнгән[8] дини һәм дөньяви мәсьәләләрне чишү тәҗрибәсен тормышчан итеп сакларга мөмкинлек бирә.

Аллаһ Сүбханә вә Тәгалә Муса Ярулла Бигиевка шәфкать күрсәтсен, ислам файдасына булган хезмәтләрен кабул итсен һәм аңа мәрхәмәтен вә киң рәхмәтен насыйп әйләсен!

Бу проектны гамәлгә ашыруны Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте рәисе мөфти шәех Равиль хәзрәт Гайнетдин фатихасы белән башлап җибәрдек. “Муса Бигиев мирасы” сериясенең җаваплы мөхәррире һәм китапны тәрҗемә кылучы А. Г. Хәйретдиновка ихлас күңелдән рәхмәтебезне һәм тирән ихтирамыбызны белдерәбез. Бәяләүчеләр: Ислам Зарипов, тарих фән. канд., Р. Адыгамов, тарих фән. канд.; җаваплы мөхәррир Р. В. Ислямов; серияне матбугатка әзерләү өчен җаваплы мөхәррирләр: Г. Ю. Хабибуллина, Р. И. Баишев; шулай ук бу проектны әзерләүгә һәм нәшер итүгә матди ярдәм күрсәтүче Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фондына чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.

Дамир МУХЕТДИНОВ,
*илаһийәт докторы, сәяси фән. канд., СПбГУ профессоры, Санкт-Петербург дәүләт университетының Ислам фәнни-тикшерү үзәге директоры, Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары, Мәскәү ислам институты ректоры*

[8] Фикх һәм шәригать мәсьәләләре түбәндәге хезмәтләрдә тирәнтен рәвештә каралган: *Тахмаз А. М.* Ханафитский фикх. М.: ИД «Медина», 2013. Т. 1. 366 с., Т. 2. 324 с.; *Гайнутдин Р.* Ислам: вероучение, поклонение, нравственность, закон. М: ИД «Медина», 2020. 848 с.; *Шалтут М.* Ислам: вероучение и закон. М.: ИД «Медина», 2021. 740 с.; *Сюкияйнен Л. Р.* Исламское право и диалог культур в современном мире. М.: Изд. дом Высшей школы экономики, 2021. 684 с.

Муса Җаруллаһ Бигиев

# МӘЕТ ЯНДЫРУ МӘСЪӘЛӘСЕ ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНДА

Мәетләрне крематорияләрдә
яндыру хакында хөкүмәт тарафыннан
Дәүләт думасына бирелгән
закон ляихәсе[1] мөнәсәбәте белән язылды.

Санкт-Петербург
Типография М.-А. Максутова
1914

[1] *ляихә* (гарәп.) — проект.

**КЕШЕ НИНДИ ДӘ БУЛСА ЭШ ЭШЛӘГӘНДӘ ҮЗЕНЕҢ** күзаллауларына таянып, үзенең белдеге белән җинаять кыйла алса да, табигатьнең күрсәтмәсе белән хәрәкәт иткәндә, күпчелек очракларда, дөрес гамәл кыйлган булып чыга.

Табигать кешеләрне генә түгел, бәлки бөтен җан ияләрен дә аларның мәслихәтләренә[1] юнәлтә. Ихтыяри, ягъни бәндәнең үз теләге белән эшләгән эшләрендә яманлык була алса да, табигатьнең юнәлтүе, табигатьнең күрсәтмәсе һәрвакыт һидаять[2] була.

Бу хакыйкатьнең ышанычлы шаһиты Коръән кәримдә дә бар. Мәсәлән: “әл-Маидә” сүрәсенең 30–31 нче айәт кәримәләрендә кешеләрнең игътибарларына гаять ачык бер шаһит тәкъдим ителгән:

فَطَوَّعَتْ لَهُ نَفْسُهُ قَتْلَ أَخِيهِ فَقَتَلَهُ فَأَصْبَحَ مِنَ الْخَاسِرِينَفَبَعَثَ اللّٰهُ غُرَابًا
يَبْحَثُ فِى الْأَرْضِ لِيُرِيَهُ كَيْفَ يُوَارِى سَوْءَةَ أَخِيهِ قَالَ يَا وَيْلَتَا أَعَجَزْتُ
أَنْ أَكُونَ مِثْلَ هَـٰذَا الْغُرَابِ فَأُوَارِىَ سَوْءَةَ أَخِى فَأَصْبَحَ مِنَ النَّادِمِينَ[3]

Бу ике айәт кәримәдә иң әүвәлгеләрдән булган инсанның[4] иң әүвәлге гамәленнән булган ике эше безгә хикәят кыйлынган:

1) Берсе — үзенең бәрадәрен[5] үтерү җинаяте. Коръән кәримдә бу олы җинаять кешенең үзенә, кешенең үз теләгенә кайтарып калдырылу гыйбарәсе белән иңгән.

---

[1] *мәслихәт* (гарәп.) — яхшылык, файда.

[2] *һидаять* (гарәп.) — дөрес юлга чыгару; дөрес юлны күрсәтү; дөрес юлдан алып барылу.

[3] ***“Аңа аның нәфесе, үзенең кардәшен үтерүне җиңел эш итеп күрсәтте дә ул аны үтерде, шулай итеп ул олы югалту кичерүчеләрдән булып калды. Шуннан соң Аллаһ, кардәшенең җәсәден ничек яшерергә кирәк икәнен күрсәтү өчен җирдә казынган бер карга җибәрде. Ул: “Башыма олы бәла! — диде — Мин шушы каргага охшатып, кардәшемнең җәсәден яшерә алмыйммы әллә?” — диде. Шулай итеп, ул үкенүчеләрдән булып калды***” (Коръән, 5: 30–31). (Биредә һәм алга таба Коръән айәтләрен татар теленә тәрҗемә итүче — А. Хәйретдинов.)

[4] *инсан* (гарәп.) — кеше; адәм баласы.

[5] *бәрадәр* (фарс.) — ир туган, ир кардәш; абый; эне.

2) Икенчесе — бәрадәренең җәсәден[6] җиргә күмеп кую фикеренә кешенең юнәлдерелүе.

Җинаятьләрнең иң олысын кыйла алган беренче кеше һидаятьләренең иң кечкенәсеннән дә гаҗиз калган. Ягъни, бәрадәрен үтерә алган, ләкин табигать тарафыннан сабак алганчыга кадәр аның җәсәден күмеп куя алмаган. Үтерү җинаяте кешенең үз теләге белән, үз ихтыяры белән, үз белдеге белән кыйлынган иде. Җирләп кую турындагы һидаять исә, табигатьнең юнәлдерүе белән, бер карганың сабак бирүе белән бирелде.

Иң беренче "шәһид-е инсаният"[7] хөрмәтенә табигать тарафыннан иң беренче кешеләргә өйрәтелгән дәфен кыйлу[8] һидаяте башта бер табигый сөннәт[9] иде, ниһаять, күпчелек кешеләр өчен бер милли[10] сөннәт булып китте.

Сәхабә[11] Убәйй бин Кәгаб[12] Сәййидел-вөҗүд[13], галәйһис-саләтү вә-с-сәламү хәзрәтләреннән риваять итте:

أُلْحِدَ آدَمُ و غُسِلَ بالمَاءِ وِتْراً فقالَتِ المَلائِكَةُ هَذِه سُنَّةُ وَلَدِ آدَمَ مِنْ بَعْدِهِ[14]

6 *җәсәд* (гарәп.) — үлгән кешенең гәүдәсе.

7 "*шәһид-е инсаният*" (гарәп./фарс.) — кешелек дөньясының беренче шәһите, ягъни Аллаһка, Ул биргән иманга тугры калу йөзеннән, аларга хыянәт итмәү йөзеннән үлемгә дучар ителгән беренче кеше.

8 *дәфен кыйлу* — җәсәдне җирдә казылган кабергә салып күмү; җирләү.

9 *сөннәт* (гарәп.) — гадәт; теге яки бу җәмгыятьтә һәркем тарафыннан кабул ителгән эш яки эш тәртибе.

10 *милли* (гарәп.) — биредә милли сүзе теге яки бу халыкны, милләтне күздә тотмый, бәлки кешеләрнең һәммәсен дә, тереклек итүче аңлы-акыллы мәхлуклар төре буларак, күздә тота.

11 *сәхабә* (гарәп.) — Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ иярчене, аны үз күзләре белән күргән, аралашкан беренче буын мөселманнардан бере.

12 *Убәйй бин Кәгаб* (якынча 650 ваф.) — Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ нең сәхабәсе һәм сәркятибе. Коръәнне матур итеп көйләп укый алганы өчен аны *сәййид әл-курра*, ягъни *Коръән укучыларның әфәндесе*, дип атый торган булганнар.

13 *Сәййидел-вөҗүд* (гарәп.) — *Барлык Галәменең Әфәндесе*, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ нең мактаулы олуг мәртәбәсен белдерә торган атама.

14 *Хәдис* әс-Суйутыйның "Әл-Җәмигъ әл-Кәбир" җыентыгыннан, 4166; шулай ук, әл-Хиндиның "Канз-әл-Гуммәл фи сөнән әл-әквәл вә әл-әфгал" җыентыгында 42378 номеры белән бирелгән.

Ягъни: кешеләрнең бөек бабалары булган Адәм берничә мәртәбә госел кыйлынып, дәфен ителде. Шулай итеп, мәетләрнең җәсәдләрен госел кыйлып җирләү бабалары Адәмнән соң аның барлык балаларына да фитрый[15] сөннәт, милли сөннәт булды.

Коръән кәрим күпсанлы айәт кәримәләрендә бу фитрый сөннәтне раслады, куәтләде һәм вазыйфа буларак кешеләргә йөкләде:

مِنْهَا خَلَقْنَاكُمْ وَفِيهَا نُعِيدُكُمْ وَمِنْهَا نُخْرِجُكُمْ تَارَةً أُخْرَى

Ягъни: ***"Җирдән яраттык сезне, җирнең үзенә кайтарырбыз да сезне"***[16]. Бу айәт кәримәдә һәм ярату, һәм кире кайтару Аллаһның газамат[17] илаһиясенә[18] бәйләнелгән. Ягъни: һәм барлыкка китерү, һәм дәфен итү илаһи канундыр, аңа хилафлык кыйлу, ягъни аны үтәмәү рөхсәт ителми. Чөнки Коръән кәримдә Аллаһның газамат илаһиясенә бәйләнелгән нәрсәләргә каршы килмәү әдәбе мөэминнәргә йөкләнгән олы бер фарыз дәрәҗәсендәге гамәл булып тора.

خَلَقَهُ فَقَدَّرَهُ ثُمَّ السَّبِيلَ يَسَّرَهُ ثُمَّ أَمَاتَهُ فَأَقْبَرَهُ ثُمَّ إِذَا شَاءَ أَنشَرَهُ[19]

[15] *фитрый* (гарәп.) — кешегә тумыштан ук хас булган сыйфатлар, мәсәлән, Аллаһка тартылу, гаделлекне гаделсезлектән аера белү һ. б. ш.

[16] Биредә һәм алга таба Коръән кәрим айәтләре Муса Бигиев тәрҗемәсендә бирелә, әгәр автор ул айәтләрне тәрҗемә иткән булса. Бигиев тәрҗемә итмәгән очракларда һәм, гомумән, аның тәрҗемәләренең үзенчәлеген күрсәтү өчен, шул ук айәтләрнең тәрҗемәсен астөшермәләрдә А. Хәйретдинов тәрҗемәсендә дә бирәбез: "***Сезләрне аңардан [туфрактан] яраттык, кире аңарга кайтарабыз сезне һәм тагын да шуннан чыгарабыз сезне***" (Коръән, 20: 55).

[17] *газамат* (гарәп.) — бөеклек, олуглык.

[18] *газамат илаһия* (гарәп.) — бердәнбер илаһ булган Аллаһка гына хас олуглык, бөеклек.

[19] "***... аны яратты һәм үлчәмнәрен тәгаен кыйлды. Аннан соң — Юл: аның өчен җиңел кыйлды аны. Аннан соң аны үлдерде дә каберга иңдерде. Аннан соң, Үзе теләгән бер чакта аны тергезде***" (Коръән, 80: 19–22). Китапның асыл нөсхәсендә 19 нчы айәтнең башындагы ике сүз төшеп калган: (مِن نُّطْفَةٍ خَلَقَهُ فَقَدَّرَهُ) булырга тиеш, ягъни: "***бер тамчыдан аны яратты һәм үлчәмнәрен тәгаен кыйлды***".

Әлеге дүрт айәтнең бәянына күрә, кабердә дәфен ителү үлем кебек үк илаһи бер сөннәттер. Хикмәт илаһиянең[20] карары белән кешеләргә үлем ни рәвешле язылган булса, бәгъде-л-мәүт[21] аларның җәсәдләрен каберләргә дәфен иту дә икрам илаһинең[22] чагылышы буларак, кешеләргә шул рәвешле фарыз ителгән.

Бу дүрт айәт кәримәдә Аллаһның бәндәләренә карата булган ярдәмчеллеге һәм хөрмәтләве бәян кыйлынган: кешене барлыкка китерү, аның бөтен әгъзаларын тәмам итеп, аңа кодрәт бирү, кямиллеккә ирешү юлларын һәрберсе өчен җиңел иту, бәгъде-л-мәүт җәсәдләрене каберләрдә дәфен иту — бу нәрсәләрнең һәрбере кешеләргә карата Аллаһның ярдәмедер, Аллаһның кешеләрне хөрмәтләү галәмәтедер. Айәт кәримәдә үлем дә, каберләрдә дәфен кыйлу да Аллаһның нәкъ үзеннән килгән сөннәт рәвешендә, үлемнең табигый нәрсә булуы, тиешле нәрсә булуы кебек, җирләүнең дә табигыйлыгы, тиешлеге бәян ителгән.

Дәфен кыйлу, бу айәт кәримәләрнең гыйбарәләренә күрә, илаһи юмартлыктыр, ягъни Аллаһның кешеләргә карата белдерелгән ихтирамыдыр.

أَلَمْ نَجْعَلِ الْأَرْضَ كِفَاتًا أَحْيَاءً وَأَمْوَاتًا[23]

Ягъни: "***Җирнең тыш йөзен исән хәлләрендә кешеләрнең үзләренә, эч йөзен бәгъде-л-мәүт җәсәдләренә торыр урын итмәдекме?***"

Җир йөзендә кешенең исән хәлдә торуы, җир эчендә җәсәднең, бәгъде-л-мәүт, урын алуы бу ике айәт кәримәдә Аллаһның газамат илаһиясенә нисбәт кыйлынган[24].

[20] *хикмәт илаһия* (гарәп.) — Аллаһка гына хас булган тирән һәм һәрьяклап тулы булган белем.

[21] *бәгъде-л-мәүт* (гарәп.) — үлемнән соң; үлемнән соңгы.

[22] *икрам илаһи* (гарәп.) — Аллаһ тарафыннан күрсәтелгән хөрмәт, ихтирам, кадерләү.

[23] "***Тереләр булсын, үләләр булсын — Без җирне сыйдыручы итмәдекмени?***" (Коръән, 77: 25–26).

[24] *нисбәт кыйлынган* — бәйләнелгән.

Терек чакта җир йөзендә тору кешенең мөкаддәс[25] хокукыдыр. Үлемнән соң җәсәднең җир куенында урын алуы да кешенең мөкаддәс хакы булып чыга. Йортларның кешеләргә мөнәсәбәте нинди булса, каберләрнең дә мәетләргә мөнәсәбәте шундыйдыр. Торган йортыннан кешене чыгару, торыр йортыннан мәхрүм итү тыелган икән, аның җәсәден кабердән мәхрүм итү дә тыелган булып чыга.

"Кешеләрнең җәсәдләрен каберләрдә дәфен итү" рәвешендә яңгыраган илаhи сөннәт табигатьнең мәслихәтләренә дә hәрьяклап туры килә, бәлки туры килергә тиеш тә. Чөнки җирдән чыккан файдалы казылмалар, үсемлекләр, хайваннар дөньясына нисбәтән бар булу hәм таркалып юкка чыгу, тереклек итү hәм үлү кебек хәлләр булса да, табигатьнең үзенә нисбәтән бары тик даими хәрәкәт, бары тик туктаусыз рәвештә үзгәреп тору бар. Табигатьтә начар нәрсә юк, бер халәттән икенче бер халәткә күчеп торган матдә hаман да мәңге бар булып кала бирә, туктап торуны белмичә үзгәреп, агып тора. Һәрбере — җирдән чыккан үсемлекләр дә, хайванннар да, ахырда җирнең үзенә, әлбәттә, әйләнеп кайталар. Табигать үзгәрешенең бәрабәренә табигать хәзинәләренә керем килеп тора. Хикмәт илаhия мәгърифәте белән гамәлгә куелган бу үлчәү тигезлеге бәрәкәте белән табигатьтә булып тора торган вакыйгалар интизамлы[26] сурәттә дәвам итәләр; табигать бюджетында җитешсезлекләр, ялганмаган бушлыклар калмый. Табигать ул гаять моктасыйдтыр[27], ул бер бөртекне дә, бер зәррәне дә әрәм итмәс. Табигать югары дәрәҗәдәге кайгыртучы вә чара күрүче — бер зәррәне дә тынычлыкта тотып файдасыз калдырмас. Җан ияләрен терек чакларында тәрбия итүче табигать, бәгъде-л-мәүт ул җан ияләренең гәүдәләрен тарката да, саклау сандыкларында вакытына кадәр саклап тота. Кешеләрнең, хайваннарның файдаланылуыннан чыккан бөтен яхшы нәрсәләр, бөтен үлек гәүдәләр табигать фабрикаларында гаять кыйммәтле чимал булалар. Ул малларны ясалма ысуллар белән юкка чыгармыйча, табигать тарафыннан эшкәртелүгә тапшыру урынлыдыр, яки тиешледер.

[25] *мөкаддәс* (гарәп.) — изге.

[26] *интизамлы* (гарәп.) — тәртипкә салынган, кагыйдәләргә туры килгән.

[27] *моктасыйд* (гарәп.) — булганны саклап тотучы; юкка сарыф итмәүче.

Ислам фәлсәфәчесе Әбу әл-Галә[28] хәзрәтләре "Әл-Лөзүмийәт"тә[29] болай дигән:

وَمَا الْأَرْضُ إِلّا مِثْلُنَا الرِّزْقَ تَبْتَغِي فَتَأْكُلُ مِنْ هَذَا الْأَنَامِ وَتَشْرَبُ

Ягъни: *"Җир дә тәмам безнең кебидер — ризык эзли. Шуңа күрә, кешеләрнең дә, хайваннарның да тәннәрен һәм каннарын ашый"*.

Кешеләрнең җәсәдләрен каберләргә салып дәфен итү, Коръән кәримнең бәянына күрә, бөтен кешелек дөньясына нисбәтән бер илаһи сөннәт кебек булды, дидек. Бу сөннәт илаһия, даими әйләнеш ягыннан, табигатьнең мәслихәтләренә дә туры килә, дидек.

Шуңа күрә, бөтен өммәт исламия, бөтен мәзаһиб исламия[30] дәфеннең вөҗүбенә[31] иҗмагъ[32] итте[33]. Мәетләрнең җәсәдләрен каберләрдә дәфен итү би-л-иҗмагъ[34] фарыз ителде.

[28] *Әбу әл-Галә* (Әбу әл-Галә әл-Мәгарри, (973–1057/58) — мәшһүр гарәп шагыйре, фәлсәфәче, тел белгече.

[29] ***Әл-Лөзүмийәт*** (әсәрнең тулы атамасы: *Лөзүм мә лә йәлзәм* ("Тиешле булмаганнарның тиешлелеге"). Әбу әл-Галә Мәгарринең бөтен мөселман дөньясында дан казанган шигъри-фәлсәфи, тәрбияви әсәре. Автор, нинди диндә булуларына карамастан, кешеләр арасында бер-беренең инануларына ихтирам былырга тиешлеген алга сөрә, диндарлык пәрдәсе астына яшеренгән һәртөрле ырымчыларны тәнкыйтьли, дин әһелләренең хакимлегенә буйсынып, сукырларча аларның һәр әйткәненә ышанып, ияреп баручыларны шелтәли.

[30] *мәзаһиб исламия* (гарәп.) — ислам шәригате кануннары белән эш итә торган белемнең (фикъһы һәм фикъһының ысуллары/методологиясе) мәзһәбләре (юнәлешләре): хәнәфи мәзһәбе, шәфигый мәзһәбе, мәлики мәзһәбе, хәнбәли мәзһәбе.

[31] *вөҗүб* (гарәп.; тиешлек; шулай ук: *ваҗиб* — тиешле) — үтәлергә тиешле дини вазыйфа; мөселманнарга йөкләнгән булганына күрә эшләнми калмаска тиешле булган гыйбадәт төре (мәсәлән ваҗиб намаз), эш яки гамәл. Фарыздан аермалы буларак, ваҗибне үтәмәгән мөселман ислам диненнән ваз кичүче (мөртәт) буларак танылмый, ә фарызны инкяр итсә — ислам диненнән чыгарыла.

[32] *иҗмагъ* (гарәп.) — шәригать хөкемнәрен булдыру алымнарының берсе: дин галимнәренең бердәм төстә яки күпчелегенең нинди дә булса бер шәргый (шәригатькә кагылышлы) мәсьәләне чишкәндә уртак фикергә килүләре, уртак бер карарга килеп үзара ризалашулары.

[33] *иҗмагъ итте* (гарәп.) — уртак фикергә, уртак карарга килде.

[34] *би-л-иҗмагъ* (гарәп.) — *иҗмагъ белән*, ягъни: дин галимнәренең уртак фикере, уртак карары нигезендә.

Дәфеннең važиблеге[35] берничә нигез өстенә корылган.

1. Беренче нигез — инсанның җәсәденә ихтирам күрсәтү нигезедер.

Шаригъ хәким[36] Сәййидел-вөҗүд[37] галәйһис-саләтү вә-с-сәламү хәзрәтләренең тәгълимнәренә[38] күрә, кешенең үзе дә, җәсәде дә, һәм терек чагында, һәм үлгәннән соң да таһирдыр[39], мөхтәрәмдер. Хайван лашәсе[40] кебек, кешенең дә җәсәден җирләмичә калдыру, яки мөхтәрәм гәүдәсен утта яндыру, яисә кош-кортларга ату кешенең хөрмәтенә нисбәтән бик яман мыскыл итү, кимсетү була. Шуңа күрә, мәетнең җәсәден юу, хәленә туры килгән сурәттә кәфенләү, әзерләү, кабасы хозурында җеназа намазы уку, каберенә кадәр җәмәгать белән озата бару, ниһаять, кабердә ләхет эченә урнаштырып дәфен итү — болар һәммәсе дә кеше җәсәденә ихтирам күрсәтү йөзеннән, динебездә фарыз ителгән[41].

2. Икенче нигез — һаваны, җир йөзен зарарлы нәрсәләрдән, черекләрдән-бозыклардан, зыянлы матдәләрдән арындыру нигезе.

Җан чыкканнан соң, мәгълүм, әлбәттә, һәр хайванның лашәсе бозыла, исләнә. Ул ис һаваны боза; зыянлы матдәләрнең тәэсире белән һава агулана. Лашәләр күпчелек очракларда йогышлы авыруларның гонсырларын[42] да һавада тараталар. Бу хадисәләргә[43] каршы торуның иң яхшы, иң җиңел алымы — мәетләрне йортлардан,

---

[35] *важиб* (гарәп.) — фикъһы (ислами хокук белеме) төшенчәсе — шәригать тарафыннан эшләнергә тиешле гыйбадәт яки гамәлне белдерә; кайбер мәзһәбләрдә фарызга тиң булган нәрсә хөкемендә йөри; мәзһәбенә күрә важибне үтәмәгән мөселман ислам диненнән ваз кичүче (мөртәт) буларак танылмый, ә фарызны инкяр итсә — ислам диненнән чыгарыла.

[36] *Шаригъ хәким* — Хикмәт иясе булган шәригатьче, автор бирердә Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ не күздә тота.

[37] *Сәййид әл-вөҗүд* (Барлыкның әфәндесе) — Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ не олылау гыйбарәсе.

[38] *тәгълим* (гарәп.) — өйрәтү; гыйлем бирү, гыйлемләндерү.

[39] *таһир* (гарәп.) — саф, ару, чиста.

[40] *лашә* (фарсычадан) — үле гәүдә; үләксә.

[41] Бу темага караган сорауларга тулырак мәгълүмат алу өчен, карагыз: Гайнетдин Р. Югарыда атап күрсәтелгән хезмәт, 337–346 б.; шулай ук: Китаб ал-Джаназа (Книга о джаназа) / сост. А. Муслимов. Н. Новгород: ИД "Медина", 2007. 207 с. — Җ. М. искәрмәсе. Шартлы билгеләр: *Б. М.* — сериянең баш мөхәррире Д. В. Мухетдинов искәрмәләре; *Т.* — тәрҗемәче, сериянең җаваплы мөхәррире А. Г. Хәйретдинов искәрмәләре; *Җ. М.* — җаваплы мөхәррир Р. В. Ислямов искәрмәләре.

иген җирләреннән, бакчалардан читтә булган бер җирдә, кырда, сахрада, тирән чокырларда дәфен итмәктер.

Кабердә мәетнең җәсәде аз вакыт эчендә чери; ягъни аны тәшкил иткән бөтен әгъза-өлешләр, матдәләр кире үзләренең асылларына кайталар. Шул рәвешле, табигать хәзинәләренең икътисад сандыкларына олы ярдәм күрсәтелә. Үләрне дәфен итү сәбәпле исәннәр мәетләрнең авыр исләреннән интекмәс, начар күренешләр исәннәргә дәһшәт[44] бирмәс. Ягъни иң җиңел, иң кулай бер чара ярдәмендә һәм ихтирам күрсәтү вазыйфасы, һәм сәламәтлекне саклау таләпләре, һәм табигатьнең үз икътисады тәэмин ителгән була.

Шуңа күрә, бөтен кешелек дөньясында мәетләрне каберләрдә дәфен итү кебек сөннәт илаһия гомуми сурәттә кабул кыйлынган. Шуңа күрә, иң әүвәлге шәһид-е инсаният, табигатьнең ишарәсе нәтиҗәсендә, дәфен кыйлынган.

Югарыда инде әйттек: табигатьнең ишарәләре, күпчелек очракларда, һидаять була; нәтиҗәләренә нисбәтән дә һәрвакыт зарарсыз булып чыга.

Ихтимал, вәхшәт[45] дөньясында мәетләрнең лашәләренә карата, бәлки, башка төрле мөгамәләләр дә булгандыр. Дөрестән дә, Һиндыстан кебек, Япония кебек һәм югары мәдәният, һәм көчле диянәт дөньясында мәетләренең җәсәдләрен утта яндыру кебек дини гадәт иң борынгы заманнардан башланып, бүгенгә кадәр дәвам итеп килә.

Мәдәни һәм диндар ул милләтләр мөкаддәс диннәренең фәрманы белән, мәгъбүднең[46] ризалыгына ирешү максаты белән,

[42] *гонсыр* (гарәп.) — нинди дә булса матди җисемнең аерылгысыз өлеше; матди галәмнең элементлары; нәрсәнең дә булса табигате, асыл сыйфаты. Биредә: йогышлы авыруның таралуына сәбәп булган нәрсәләр, шул исәптән вируслар, бактерияләр, серкәләр.

[43] *хадисәләр* (гарәп.) — хәлләр, процесслар.

[44] *дәһшәт* (гарәп.) — куркыныч; тетрәнү.

[45] *вәхшәт* (гарәп.) — кыргыйлык; мәдәниятсезлек.

[46] *мәгъбүд* (гарәп.) — үзенә гыйбадәт ителә торган нәрсә. Мәсәлән, ислам динендә мәгъбүд — Аллаһ, кайбер халыкларда мәгъбүд Кояш булган, һинд динендә мәгъбүд булып исәбе-хисабы булмаган илаһлар торалар.

мәетләренә ихтирам күрсәтү йөзеннән мәгъбүднең дәргяһына[47], җәннәтләренә озатмак өмете белән булса кирәк, мәетләрнең җәсәдләрен утка салып яндырып бетерә иделәр.

Ислам фәлсәфәчесе Әбу әл-Галә хәзрәтләре "Әл-Лөзүмийәт"тә болай дигән:

أُولَئِكَ يَحْرِقُونَ الْمَيْتَ نُسْكًا     وَيُشْعِرُهُ لُبَانًا مُلْهِبُوهُ[48]

Ягъни: "*һинд динен тотучыларда мәетләрне яндыру дини йола, гыйбадәт иде*". Әһл-е ислам[49] Мәккә хәрәмнәренә[50] китерелгән кашка[51] корбаннарын ничек багышласалар, һинд динен тотучылар да Аллаһның дәргяһына озатылачак мәетләрен лүбан[52] кебек хуш исле төтен белән шулай багышлыйлар.

Ислам әдәпләренең гүзәллеге, минем карашымча, үзе үк изгелекнең бер күрсәткече, бер дәлиледер. Алай булса да, мин башка милләтләрнең дини әдәпләренә каршы чыгудан, аларны тәнкыйтьләүдән сакланам.

Будда мәзһәбендә мәет яндыру исламияттә мәетне дәфен кыйлу кебек бер гыйбадәттер, дини бер әдәптер. Мондый хосусларда фәйләсүф Әбу әл-Галә хәзрәтләренә кушылып, аның белән бергә:

سِيَّانِ إِلْبَاسُهُ مَا لَانَ مِنْ كَفَنٍ     وَطَرْحُهُ فِي لَظىً لِلنَّارِ مُحْتَدِمِ[53]

---

[47] *дәргяһ* (фарс.) — ишек алды; биредә мәгъбүднең хозурына озату мәгънәсендә кулланылган.

[48] гарәпчәдән тәрҗемәсе: "*Мәетләрен утта яндыручылар дини йолаларын үтәүчеләр иде / йолаларын үткәргәндә алардан исле төтен таралыр иде*" (әл-Мәгарринең Әл-Лөзүмийәтеннән) — *Җ. М. иск.*

[49] *әһл-е ислам* (гарәп.) — ислам динен тотучылар; мөселманнар.

[50] *Мәккә хәрәмнәре* — Мәккәдә хаҗ йоласы үтәлә торган изге урыннар; *хәрәм* җирлеге Мәккә әйләнәсендәге микатларны (хаҗ һәм гомрә кыйлырга килүчеләрнең ихрам хәленә керергә тиешле булган чикләрне) кичкәннән соң башлана.

[51] *кашка* — корбан итеп чалыначак малга сугылган тамга.

[52] *лүбан* (гарәп.) — кайбер диннәрдә дини йолалар үткәргәндә исле төтен тарату өчен ягыла торган махсус сагыз; (ладан).

[53] гарәпчәдән тәрҗемәсе: "*Бер үк нәрсә — мәетнең җәсәден йомшак кәфеннәргә төреп дәфен кыйлу/ я дөрләп янган ялкын эченә мәетнең җәсәден ыргыту*" (әл-Мәгарринең "Әл-Лөзүмийәт"еннән) — *Җ. М. иск.*

дип әйтә алабыз. Ягъни: “*Йомшак кәфеннәргә урап мәетнең җәсәден дәфен кыйлу, янып дөрләп торыр ялкын эченә мәетнең җәсәден ату — һәрбере бәрабәрдер*”[54].

Кеше үзенең фикерен, үзенең карашын бер мәсьәләдә тарафларның кайберләренә сыйдырып чикләсә, мәет якмак кебек дини әдәпләрне, бәлки, урынлы дип тә таба алыр. Ислам фәлсәфәчесе Әбу әл-Галә хәзрәтләре “*Әл-Лөзүмийәт*”тә болай дигән:

فَاِعجَب لِتَحريقِ أَهلِ الهِندِ مَيتَهُمُ     وَذاكَ أَروَحُ مِن طولِ التَباريحِ
إِن حَرَّقوهُ فَما يَخشَونَ مِن ضَبُعٍ     تَسري إِليهِ وَلا خَفيٍّ وَتَطريحِ
وَالنارُ أَطيَبُ مِن كافورِ مَيِّتِنا     غِبّاً وَأَذهَبُ لِلنَكراءِ وَالريحِ[55]

Ягъни: “*Мәетләрне яндыру яхшырак. Дәфен кыйлу кебек озын-озын мәшәкатьләре, зур чыгымнары юк, хәтәре дә юк. Ялкын безнең мәетләрнең кяфурләреннән*[56]*, ахыр чиктә, күпкә пакьтер; җир йөзеннән черек лашәләрне, авыр исләрне аз вакыт эчендә юкка чыгара*”.

Һәр кешенең фикеренә, һәр милләтнең дини әдәпләренә ихтирам күзе белән карасак, мондый сүзләрне иркен сурәттә әйтү, әлбәттә, рөхсәт ителә.

Мәетләрне яндыру мәсьәләсе турында киләчәк гасырларга кагылышлы сурәттә, яки бу гасырда ук кайбер урыннарга кагылышлы сурәттә фикер йөртсәк, мәетләрне яндыру файдасына куәтле дәлилләр табылырга мөмкин: җир йөзендә гомран[57], мәдәният

[54] *бәрабәр* — бергә, бергәләп, бергәлектә.

[55] гарәпчәдән тәрҗемәсе: “*Һинд динен тотучыларның мәетләрне яндыруы гаҗәп/ моның дәфен кыйлырга әзерләнү кебек озын мәшәкатьләре юк/ яндырган очракта ерткыч гиена/ үзенә азык эзләп каберне казып мәсхәрәли алмас/ Ялкын мәетләрдән таралучы камфара исеннән пакътер / ут авыр исләрне юкка чыгара*” (әл-Мәгарринең “Әл-Лөзүмийәт”еннән) — *Җ. М. иск.*

[56] *кяфур* (гарәп.) — кяфур (кайбер исле үсемлекләрдән житештерелә торган татлы исле матдә; хуш исле май, хушбуй; (камфора).

[57] *гомран* (гарәп.) — эшкәртелгәнлек; төзеклек; кеше кулы белән, хезмәте белән корылган мохит.

тәрәкъкый[58] иткән саен, елдан-елга, гасырдан-гасырга кешеләрнең саны һаман-һаман, әлбәттә, артачактыр. Мәгъмүр мәркәзләрнең[59] тирә-ягында җитәрлек кадәр буш җир табу гаять авыр булачак. Мәетләрнең күплеген, җирләрнең тарлыгын, каберстаннарның ераклыгын, чыгымнарның күплеген исәпкә алганда, дәфен кыйлу гаять мөшкел бер эш булачак. Каберстан тулып беткәннән соң да дәфен кыйлу һаман дәвам иттерелсә, ул чакта каберстандагы бозык, черек нәрсәләрнең, чак матдәләрнең һавада таралуы кешеләргә дә, хайваннарга да зур куркыныч булачактыр. Андый хәлдә, мәетләрне яндыру иң җиңел, иң яхшы чара булып чыга.

Ислам фәлсәфәчесе Әбу әл-Галә хәзрәтләре "Әл-Лөзүмийәт"тә болай дигән:

غَسَلَ المَليكُ بِلادَهُ مِن أَهلِها　　بِالماءِ إِذ جاؤوا بِسوءِ شَنارِ

وَيُقالُ إِنَّ اللهَ جَلَّ ثَناؤُهُ　　يَوماً يُطَهِّرُ أَرضَهُ بِالنارِ

Ягъни: "*Кешеләрнең шакшылыкларыннан җир йөзен туфан сулары белән Җирнең Мәлиге*[60] *бер вакыт юган иде. Бер вакыт килер, кешеләрнең лашәләреннән җир йөзен ут белән пакьләмәк кирәк булыр*".

Фәйләсүф кисәтеп әйткән ул вакыт кайбер мәмләкәтләргә нисбәтән нәкъ бүген инде килгән булса кирәк.

Мәетләрне яндыру турында югарыда әйтелгән уй-фикерләр, әйтик, тугрыдыр. Ләкин мәетләрнең җәсәдләрен каберләрдә дәфен итү әдәпләре хакында исламиятнең аңлатулары тагын да тугрырактыр, тагын да югарырактыр.

1. Халәкатьнең[61] гаҗәеп сәнагатенә[62], ягъни кешенең мөхтәрәм гәүдәсенә ихтирам күрсәтү вазыйфасы — ул гәүдәне дәфен итүдән

[58] *тәрәкъкый* (гарәп.) — кешеләр яшәешенең уңай якка үсеш-үзгәреше; прогресс.

[59] *мәгъмүр* — кешеләр яши торган урын; кеше кулы белән төзек хәлгә китерелгән.

[60] *мәлик* (гарәп.) — патша.

[61] *халәкать* (гарәп.) — Аллаһ тарафыннан барлыкның булдырылышы, барлыкка китерелүе.

[62] *сәнагать* (гарәп.) — ясалыш; төзелеш.

гыйбарәт. Терек чагында кешенең гәүдәсе мөхтәрәм нәрсә иде. Үлем ул хөрмәтне юкка чыгармый. Хөрмәт тумыштан бирелгән хокуктандыр; фәкыйһләрнең[63] горефенә күрә аңлатсак, хөрмәт — илаһи хокуктандыр. Хәтта кеше үзе дә үзенең гәүдәсенә зыян китерә алу хокукыннан мәхрүмдер. Үзенең җәсәден үлгәннән соң яндыру хакында бер кеше исән чагында васыять калдырган булса, аның андый васыяте үтәлмәс. Изге хокукка орынуны, аны бозуны күздә тоткан андый васыять, гомумән, һәрвакыт буш булыр, гамәлгә ашырылмас.

Өмме-л-мөэминин[64] сәййидә Гаишә[65], өмме-л-мөэминин сәййидә Өмме Сәләмә[66] хәзрәтләре болай дип риваять иткәннәр:

بُنْيَةُ الْإِنْسَانِ فِي مَمَاتِهِ كَبُنْيَتِهِ فِي حَيَاتِهِ
كَسْرُ عَظْمِ الْمَيِّتِ مِثْلُ كَسْرِ عَظْمِ الْحَيِّ[67]

Бу гомуми мәгънәгә ия булган хәдисне Әбу Давыд[68], Ибне Маҗә[69] кебек бөек имамнар риваять итеп, Ибне Маҗә хәзрәтләре (فِي الْإِثْمِ) сүзен

[63] *фәкыйһ* (гарәп.) — шәригать хөкемнәре белгече, шәригать кануннарын булдыручы дин галиме.

[64] ***Өмме-л-мөэминин*** (күплек санында *өммәһат әл-мөэминин*) — "Мөэминнәрнең аналары" дигән гыйбарә пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ белән никяхта булган хатыннарның, ул үлгәннән соң кияүгә чыгулары тыелган булуын күздә тота, ягъни һичбер мөэмин үзенең анасына өйләнә алмаган кебек, пәйгамбәрдән калган хатыннарның берсен дә, үз анасы дәрәҗәсендә булганга күрә, никяхлый алмаган.

[65] ***Гайшә*** (милади 678 ваф.) — Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ хәләл җефете, шулай ук, пәйгамбәребезнең иң якын сәхабәләреннән булган Әбу Бәкернең кызы.

[66] ***Өмме Сәләмә*** (милади 681 ваф.) — тулы исеме: Өмме Сәләмә Һинд бинт Әбу Өмәййә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ хәләл җефете, 84 яшендә вафат. Өмме Сәләмәнең ире Әбу Сәләмә Өхед явы чагында алган ярадан үлгәннән соң, Расүле Аллаһ аның белән 626 елның март аенда никяхлана. Өмме Сәләмә пәйгамбәребезнең ханымнары арасында иң соңыннан вафат иткәне.

[67] гарәпчәдән тәрҗемәсе: «*Үлгән кешенең гәүдәсе аның исән чагындагы гәүдәсе кебек — мәетнең сөякләрен сындырмак тере берәүнең сөякләрен сындырмак кебидер*». Муса Бигиев китергән хәдисне таба алмадык, әмма мәгънәсе белән охшаш хәдисләр бар. (Карагыз: *Сөнән Әбу Давыд*, 3207; *Сөнән Ибн Маҗә*, 1616)

[68] ***Әбу Давыд*** (милади 817–889) — Әбу Давыд әс-Сиҗҗистани, мәшһүр хәдисче галим, ислам дөньясында хәдисләр буенча төп чыганак булып саналган "Алты хәдисченең китабы", ягъни гарәпчә "Көтеб ситтә"дән "Сөнән Әбу Давыд" исемлесен туплаган белгеч.

[69] ***Ибне Маҗә*** (милади 824–887) — мәшһүр хәдисче галим, "Көтеб ситтә"нең алтынчы китабы булып саналган "Сөнән ибне Маҗә" исемлесен туплаган кеше.

дә кушкан[70]. Шаригъ хәкимнең бу киң мәгънәле сүзләре фәкыйһләрнең иҗтиһадларына[71] бер нигез ителде. Шуңа күрә мәетнең җәсәден утта яндырып юкка чыгару бөтен фәкыйһләрнең карашларынча, би-л-иҗмагъ, тыелган. Мәетнең кайбер әгъзаларын сындыру, яки кисеп ату, бу эшне эшләүчене җәзага һәм җаваплылыкка тартуны тиешле итмәсә дә, би-л-иҗмагъ, ясак кыйлынган бер эштер.

Карынында алты айлык баласы булган бер хатын, әйтик, вафат булды ди, яки үтерелде ди. Карындагы балада хәрәкәт итү кебек җан әсәре бар, диик. Бу мәсьәләдә фәкыйһләрнең карашлары аерылган: садәт хәнәфия[72] карашына күрә, карынны ярып, яралгыны алу тиеш була. Чөнки яралгының үлеменә сәбәп булачак гәүдәнең хөрмәте санга сугылмый. Садәт хәнбәлия[73] карашында исә карынны яру хәрамдер, чөнки яралгының фаразый тереклеге өчен хатынның хокук тарафыннан расланган һәм танылган хөрмәте фида кыйлына алмый. Ике карашның берсен сайлап алу максаты белән түгел, бәлки кешенең хөрмәтенә фәкыйһләрнең карашларын күрсәтү нияте белән бу мәсьәләне биредә китердем.

Кодрәт иясенең кулы белән, табигать кебек иң бөек рәссамның мәгърифәте белән, осталыгы белән төзелгән изге мөкаддәс һәйкәлне, ягъни адәм баласының мөхтәрәм гәүдәсен ясалма юл белән юкка чыгару яраган нәрсә түгел; бәлки табигатьнең үз карамагына тапшыру күпкә яхшырактыр.

2. Дәфен кыйлу кешеләрнең рухи әхвәлләренә иң ятышлы нәрсә; мәет вәлиләренең[74] хәтерләре тарафыннан кабул ителү ягыннан

70 (فِي الْإِثْمِ) сүзенең гарәпчәдән тәрҗемәсе: «*гөнаһта*», ягъни бу сүз кушылгач хәдиснең тәрҗемәсе болай булачак: «*Үлгән кешенең гәүдәсе аның исән чагындагы гүдәсе кебек — мәетнең сөякләрен сындырмак тере берәүнең сөякләрен сындыруга тиң булган гөнаһтыр*».

71 *иҗтиһад* (тырышлык; эшне җиренә җиткереп башкару) — дини гыйлемгә ия булган галимнең фикъһы (хокук), яки илаһият белеме (теология) өлкәләрендә тикшеренү нәтиҗәсендә нинди дә булса карарга, хөкемгә килүе.

72 *садәт хәнәфия* — имам Әбу Хәнифә (699–767) исемен йөртүче фикъһы мәзһәбенең аталы галимнәре.

73 *садәт хәнбәлия* — имам Әхмәд ибне Хәнбәл (780–855) исемен йөртүче фикъһы мәзһәбенең аталы галимнәре.

74 *мәетнең вәлиләре* — вафат булган кешенең туган-тумачасы, дус-ише, яки аны җирләү өчен җаваплы булган кешеләр, аның вәкилләре.

да иң туры килә торган бер сөннәт хәсәнәдер[75]. Акылын, калебен яулап алган мөкаддәс бер куәтнең фәрманы булмастан, яки утта бөек бер изгелек булуына ышану булмастан, кеше карендәшенең җәсәден утка атмас.

3. Дәфен кыйлу һәр җирдә, һәрвакыт мөмкин. Дәфен кыйлу арзан, аның чыгымнары аз, манзарасында[76] дәһшәт юк. Ул чиркану уятмый торган кулай һәм яхшы булган борынгы бер сөннәттер.

Дөрес, бүген мәдәниятнең ясалма һәм купшы мәрасименә[77] туры китереп дәфен итү гаять авырдыр. Матди чыгымнар гаять күп була. Ләкин гөнаһ дәфеннең үзендә түгел, гөнаһ, бәлки, файдасыз мәрасимдәдер. Садә[78] генә бер тәртип буенча дәфен кыйлуның хәраҗаты[79] аз була. Дәфен кыйлуның мәрасиме садәләштерелсә, авырлык калмас.

4. Каберләр һәм каберстан хакында тиешле шартлар тулысынча ригая ителсә[80], шәһәрләр, авыллар өчен каберстанның зарары булмас.

Каберстаннарны шәһәрдән, авылдан, игенлек җирләрдән, бакчалардан, коелардан, су юлларыннан ерак җирдә, читтә, кыр-сахрада ясау тиешле. Каберстанның коры урында урнашуы шарттыр. Сазлык җире каберстан ясау өчен, фәкыйһләрнең бәяннарына күрә, туры килми.

Җирләрнең хәленә күрә, каберләрне тирән итү тиештер.

Әһле хәдиснең риваятенә күрә, Шаригъ хәким галәйһис-саләтү вә-с-сәламү хәзрәтләре болай дип боерган:

إِحْفِرُوا وَأَوْسِعُوا وَأَعْمِقُوا[81]

[75] *сөннәт хәсәнә* (гарәп.) — күркәм гадәт; матур гадәт.

[76] *манзара* (гарәп.) — күренеш.

[77] *мәрасим* (гарәп.) — рәсмиләштерелгән йола; нинди дә булса рәсми вакыйганы (исем кушу, туй, җеназа һ. б. ш.) үткәрү, башкарып чыгу тәртибе.

[78] *садә* (фарс.) — саф; гади; катлаулы булмаган.

[79] *хәраҗат* (гарәп.) — чыгымнар.

[80] *ригая итәргә* — кайгыртырга; үтәргә; нинди дә булса эшне җиренә җиткереп башкарып чыгарга.

[81] гарәпчәдән тәрҗемәсе: “*Казыгыз, киңәйтегез, тирәнәйтегез*”. (*Сөнән әт-Тирмизи*, 1713; *Мөснәд Әхмәд*, 16254).

Мөхәддисләрнең[82], фәкыйһләрнең бәяннарына күрә, кабернең тирәнлеге, гадәттә, ике зирагъ[83] була. Җир астында чыга торган суларга ирешмәү шарты белән, кабер тирәнлеген арттыру рөхсәт ителә. Ләкин кешенең җәсәден җир асты суларына кадәр иңдерү фикъһы китапларында, нидәндер, тыелган[84].

Каберләрне череп ятучы җәсәднең исе чыга алыр кадәр сай итү дә тыела. Җир өстендә саганак эчендә[85] мәетләрне дәфен итү катгый сурәттә хәрамдер.

Хәдис китапларында:

عَنْ عَلِيٍّ بَعَثَنِي رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ

أَنْ لا تَدَعَ تِمْثَالاً إِلَّا طَمَسْتَهُ وَلا قَبْرًا مُشْرِفًا إِلَّا سَوَّيْتَهُ[86]

дигән хәдис катгый сөннәт буларак риваять кыйлынган[87]. Никадәр катгый исә дә, никадәр акылга ятышлы бер нәбәви фәрман исә дә, бөтен галәм-е исламияттә, һәр җирдә, һәрзаман ул кискен рәвештә санга сугылмаган. Төркистан, Һиндыстан, Мисыр, Төркия, Истанбул — һәммәсе бу олы бәла шомлыгы белән хәрап булдылар![88]

Шәһәр эчендә, авыл эчендә мәетләрне дәфен итү тыела. Мәсҗед эчендә кабер, яки кабер өстенә мәсҗед бина итү катгый рәвештә

[82] *мөхәддисләр* (гарәп.) — Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ хәдисләрен, аларның тапшырылу юлларын (иснадларын) өйрәнүче, хәдис җыентыкларын төзүче дин галимнәре.

[83] *зирагъ* (гарәп.) — терсәк; ара (озынлык) үлчәме буларак 0.66 м. тәшкил итә.

[84] моны куркынычсызлык кагыйдәләреннән чыгып аңлатырга мөмкин: суга органика калдыклары эләгеп, тирә-юньгә таралмасын өчен. — *Б. М. искәрмәсе.*

[85] *саганак* (гарәп.) *эчендә* — коеп яуган яңгыр астында.

[86] гарәпчәдән тәрҗемәсе: "*Сын икән, аны җимермичә калмагыз, җир өстендә калкып торган кабер икән — аны җир белән тигезләмичә калмагыз*".

[87] хәдисне берничә җыентыкта табарга мөмкин: *Сахих Мөслим*, 969; *Мөснәд Әхмәд*, 1/96; *Сөнән Әбу Давыд*, 3218, *Сөнән әт-Тирмизи*, 1049. — *Ж. М. иск.*

[88] ихтимал, биредә автор: изгеләр каберләренә чиксез табыну нәтиҗәсендә, мөселман дәүләтләренең фикерләүдә һәм сәясәттә төшенкелеккә, өметсезлеккә бирелүен күздә тотадыр. — *Б. М. иск.*

тыелган[89]. Кәлисәләрдә[90] ислам намазын укымак рөхсәт ителсә дә, кабер өстенә бина кыйлынган мәсҗеттә намаз уку, фәкыйһләрнең бәяннарына күрә, һич рөхсәт ителми.

Зарурәт[91] сәгатьләрендә берничә мәетне күмәк бер кабердә дәфен итү мәшругъ[92] исә дә, гадәти хәлләрдә һәр кешенең үзенә махсус кабере булырга тиеш. Гомуми каберстанда бер кабердә дәфен ителү һәр кешенең хакыдыр. Кабернең озынлыгы, әлбәттә, һәр кешенең үз буена туры китерелергә тиеш, киңлеге исә шул озынлыкның яртысын тәшкил итәргә тиеш.

Кәфен һәм җәсәдне кәфенләү, гадәттә, фарыз булса да, кыйммәтле нәрсәләрне мәетнең каберенә салып әрәм итү таләп ителми. Дөрес, Сәйиде-л-вөҗүд Шаригъ хәким, галәйһи-с-саләтү вә-с-сәламү хәзрәтләренең мөкаддәс каберләре ак[93] катыйфә[94] белән түшәлгән иде. Ләкин болай ителү әсхаб кирамның[95] теләге яки

89 кабер өстенә мәсҗед төзергә тыелу, аерып әйткәндә, ошбу хәдискә таяна: "Дөреслектә, сезгә кадәргеләр пәйгамбәрләренең һәм тәкъваларының каберләрен мәсҗедләргә әвереләдерделәр. Каберләрегезне мәсҗедләргә әйләндермәгез, сезгә бу тыелган" (*Сахих Мөслим*, 967). — *Җ. М. иск.*

90 *кәлисә* (гарәп.) — чиркәү.

91 *зарурәт* (гарәп.) — чарасызлык, ирексезлек; мәҗбүр булу.

92 *мәшругъ* (гарәп.) — шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән нәрсә яки эш.

93 Ибн Габбас сүзләреннән риваять ителгән хәдистә тукыма кызыл төстә булуы хәбәр ителә (*Сахих Мөслим*, 967). Әлеге вакыйга икенче бер хәдистә дә риваять ителә: «Аллаһ илчесенең җәсәден кабергә Гали ибне Әбу Талиб, Әл-Фазыл ибне Габбас, Кусам ибне Габбас һәм Шукъран, Аллаһ илчесенең ирекккә җибәрелгән хезмәтчесе, кабергә төшерделәр. Гавес ибне Хәүли, Гали ибне Әбу Талибтан, аңа да Аллаһ илчесенең каберенә төшәргә, күмүдә катнашырга рөхсәт итәргә сорады. Әбу Талиб аңа: "Төш!" диде. Гавес башкалар белән бергә кабергә төште. Аллаһ илчесен инде кабергә куеп, күмә башлаганда, мөхтәрәм нәбинең ирекккә җибәрелгән хезмәтчесе Шукъран, Пәйгамбәребез ﷺ ятагына җәелә торган бәрхет тукыманы кулына алып, "Аллаһ белән ант итәмен, синнән соң аны беркем дә, беркайчан да куллана алмас!" — дип сөйләнеп, кабергә күмә. Шулай бу тукыма Пәйгамбәр белән бергә кабергә күмелә» (*Сөнән Ибн Маҗә*, 321). — *Җ. М. иск.*

94 *катыйфә* (гарәп.) — бәрхет тукыма.

95 *әсхаб кирам* (гарәп.) — хөрмәтле сәхабәләр, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ чакыруына ул үзе исән чакта ияргән, аны күргән, аның белән аралашкан кешеләр һәм беренче буын мөселманнар.

кушуы белән түгел иде; бәлки, бары тик мөхтәрәм нәбинең Шукъран исемле хезмәтчесенең тырышлыгы белән эшләнгән эш иде.

Җәсәдләрне каберләргә табутларда иңдерү турында Шаригъ кәбир, галәйһис-с-саләтү вә-с-сәламү, хәзрәтләреннән дә, әсхаб кирамнан да бер хәбәр тапшырылмаган булса да, табутларда дәфен итү мәшругътыр, ягъни шәригать тарафыннан рөхсәт ителәдер[96].

Кабернең кыйбласы ягында ләхет ясау мөмкин булса, кешенең җәсәденә ихтирам күрсәтү йөзеннән, ләхет алу яхшырак. Комлык, яки җирнең йомшаклыгы сәбәбе белән ләхет алу мөмкин булмаса, каберне ләхетсез итү дөрес була.

Кешенең үлеме катгый сурәттә расланган булса, җеназаны ашыктыру мөстәхәб[97] була. Мәетне өйдә озак тоту аның якыннарының күңелләренә авырга килүе ихтималына күрә, Шаригъ хәким, галәйһис-с-саләтү вә-с-сәламү хәзрәтләре болай боерган:

عَجِّلُوا بِالْمَيِّتِ فَإِنَّهُ لَا يَنْبَغِي لِجِيفَةِ مُسْلِمٍ أَنْ تُحْبَسَ بَيْنَ ظَهْرَانَيْ أَهْلِهِ[98]

*Ләкин бер сәбәп булса, көтеп тору рөхсәт ителә, хәтта ваҗиб була.*

Шаригъ кәбир Нәби мөхтәрәм, галәйһис-с-саләтү вә-с-сәламү, хәзрәтләре дүшәмбе көн, иртәнге сәгать сигез-тугыз араларында вафат булды. Сишәмбе көн, чәршәмбе кичәсендә[99], төн уртасыннан

---

96 табутларда дәфен итү турында ислам галимнәре арасында фикерләр төрле. Хәнәфи галимнәре табут куллану, хәтта таштан я тимердән ясалган булса да, рөхсәт ителә, дип исәплиләр. Шәфигый мәзһәбе галимнәре моны күңелгә ятмаган эш дип саныйлар, әмма аерым очракларда табутта күмү мөмкин, диләр. Мәликиләр табутта күммәү дөресрәк булыр, диләр. Хәнбәлиләр, үлгән кешенең җәсәден табутта күмү кабул ителмәгән эш, Пәйгамбәребез һәм аның сәхабәләре тарафыннан безгә бу турыда тапшырылмаган, дигән караштa торалар. (Бу турыда карагыз: Сборник фетв / сост. и отв. ред. И. А. Ганиев; под общ. ред. И. Р. Аляутдинова / Централизованная религиозная организация Духовное упр-е мусульман РФ. М.: ИД «Медина», 2021. С. 113–114). — *Б. М. иск.*

97 *мөстәхәб* — хупланыла торган; мактаулы.

98 гарәпчәдән тәрҗемәсе: “*Мәет белән ашыгыгыз, чынлыкта мөселманның лашәсе аның йорттaшлары арасында саклaнырга тиеш түгел*” (*Сөнән Әбу Давыд*, 3159).

99 “*Сишәмбе көн чәршәмбе кичәсендә*” — шәригать буенча яңа көн кояш баегач башлана, шуңа күрә биредә сүз сишәмбе көн кояш баеганнан соң башланган чәршәмбе көн турында бара.

соң, сәхәр вакытында[100] дәфен кыйлынды. Шулай итеп, нәбинең җеназасы аның вафатыннан соң якынча кырык сәгать үткәч укылды.

Бер адәм дәфгый сурәттә[101], яхуд сөктә[102] кебек бер чирдән вафат булса, бер көн, ике көн; кирәк булса хәтта өч көн кадәр көтеп тору, фикъһы китапларының бәянына күрә, ваҗибтер.

Һәрхәлдә, мәетне җирләргә ашыгу яки, киресенчә, җирләмичә көтеп тору мәсьәләсе хәлләрнең төрлелегенә күрә төрле була. Үлем галәмәтләре катгый сурәттә күренсә, яки йогышлы хәстәлекләрнең бере белән вафат булса[103]; яисә мәетнең өйдә булуы андагы кешеләргә тарлык кыйлса, зарар бирсә, әлбәттә, бу сурәтләрдә ашыгу ваҗиб була. Үлемсыман гына бер хәл булса, үлемнең тәмам раслануына кадәр көтү ваҗиб була. Ләкин көтү өй әһеленә кыенлык бирсә, ул чакта мәет башка бер урынга күчерелергә тиеш.

Аңлаешлы бер сәбәп, игътибарга алынырлык бер хәл булса, мәетләрне кабердән чыгару, бер җирдән икенче җиргә, бер зираттан икенче бер каберстанга күчерү мәшругъ эш. Гасыр-ы рисаләттә[104]

[100] *сәхәр вакыты* — төннең таң атар алдындагы вакыты.

[101] *дәфгый сурәттә* — кисәк кенә, көтелмәгәндә; торган җирендә егылып.

[102] *сөктә* (гарәп.) — өянәк.

[103] Куркынычлы йогышлы чирләрдән вафат булучыларны күмү мәсьәләләрендә мөселманнар, аерым алганда русия мөселманнары, һәр заманда шул очракларга карата чыгарылган фәтваларга һәм совет законнарына таянып, акыл белән эш иткәннәр. Мәсәлән, XIX гасыр ахырында казый хәзрәт Р. Фәхретдин (1859–1936) кулы куелган “Холерадан үлгән мөселманнарны күмү турында вакытлыча кагыйдәләр”гә таянганнар. Бу кагыйдәләрдән аңлашылганча, мәетне сүләмә (агулы матдә) сеңдерелгән җәймәгә төреп, сумалаланган ящикка салып күмгәннәр. Моннан бер гасырдан артык вакыт узганнан соң, COVID-19 дип аталган йогышлы чир — коронавирус таралган шартларда, РФ мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы тарафыннан бу вакыйгаларга карата тиз арада фәтва чыгарылды. Әлеге фәтва буенча, мәетне госелсез күмү һәм, инде мөмкинлек булмаса, тәяммумсез дә күмәргә рөхсәт ителде. (Карагыз: Сборник фетв. М.: ИД «Медина», 2021. С. 104–116; *Хабутдинов А.* Ю. Лидеры российских мусульман и мусульманок в Российской империи и СССР (XIX–XX вв.). М.: ИД «Медина», 2021. С. 31–32). — *Б. М. иск.*

[104] *Гасыр-ы рисаләт* — Рисаләт (расүллек) гасыры, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ үзенең пәйгамбәрлек вазыйфаларын башкарган дәвер.

мондый хәлләр берничә мәртәбә булган. Әмире-л-мөэминин[105] хәлифә Гали[106] хәзрәтләренең җәсәде әүвәлге кабереннән, аның углы Хөсәен[107] галәйһи-с-сәлам хәзрәтләре тарафыннан чыгарылып, Күфә шәһәрендәге Касыр әл-имарада[108] дәфен ителгән.

Каберстанда каберләр арасы якынча ике терсәк кадәр калдырыла. Мәетәрне җир сыйдырышыннан артык дәфен итү кабул ителми.

Кабернең кабер, каберстанның каберстан булу вакыты җирнең, табигать-һава шартларының алмашуына күрә төрле була. Җәсәд кабердә тәмам череп, кайчан да кайчан тәмам туфракка әйләнсә, шул вакыт кабернең кабер булу вакытын тәшкил итә, кабернең кабер булу вакыты да шуның белән тәмам була. Ул кабердә башка бер кешене дәфен итмәк, я каберстанны башка максатлар өчен куллану рөхсәт ителә.

Каберлек, каберстанлык дәверенең микъдары, Коръән кәримнең бәянына күрә, йөз ел тәшкил итә:

فَأَمَاتَهُ اللَّهُ مِائَةَ عَامٍ ثُمَّ بَعَثَهُ[109]

Ягъни: йөз елдан соң җирдә әүвәлге кабернең әсәре калмый. Анда башка бер кешенең җәсәде дәфен кыйлына ала. Каберстан, йөз елдан соң, башка максатлар өчен файдаланыла ала.

Мәдинәдә Мәсҗид нәбәви[110] борынгы каберстан өстендә төзелде.

Каберстанның да бер дәвере, бер вакыты бар икән, каберстанлык мәңгелек түгел икән, киләчәк гасырларда каберстаннарның күплеге сәбәбе белән җир кытлыгыннан курку тугры булмас.

---

[105] ***Әмире-л-мөэминин*** — Мөэминнәрнең әмире, ягъни хәлифә (бу очракта Гали хәзрәтләре).

[106] ***хәлифә Гали*** (Әбу әл-Хәсән Гали ибн-е Әбу Талиб әл-Һашими әл-Кораши, якынча 600–661) — Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ тумачасы, сәхабәсе, кияве; күренекле сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, 656–661 нче елларда идарә иткән дүртенче тугры хәлифә.

[107] ***Хөсәен*** (Әбу Габдуллаһ әл-Хөсәен ибн-е Гали ибн-е Әбу Талиб, 626–680) — Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ оныгы, Гали хәлифәнең икенче угылы.

[108] ***Касыр әл-имара*** (Хөкүмәт кирмәне) — Гыйракта урнашкан Күфә шәһәренең үзәгендә VII гасыр уртасында төзелгән кирмән һәм сарай.

[109] “***...Аллаһ аны йөз елга үлдерде, аннары аны терелтте...***” (Коръән, 2:259).

[110] ***Мәсҗид нәбәви*** — Мәдинә шәһәрендә урнашкан Пәйгамбәр мәчете.

Каберстаннар хакында, мәетләрнең җәсәдләрен крематорияләрдә (гөлханнарда) яндыру хосусында, Дахилия нәзарәте[111] тарафыннан, 1913 елның 27 нче июнендә, Дәүләт думасына[112] зур кәгазьдә басылган алтмыш сәхифәлек, 802 нче нумерлы закун ляихәсе[113] бирелгән иде.

Алтмыш сәхифәлек закун ляихәсендә мәетләрне җирләүнең зарарлары, мәшәкатьләре, крематорияләрнең файдалары, җиңеллекләре тәфсилләп аңлатылган иде.

Крематория, төрекчә әйтсәк: *гөлхан* — мәетләрнең җәсәдләрен яндыру өчен махсус төзеләчәк зур бинадыр. Кызулыгы 850 дәрәҗә булачак зур мичләрдә янып торган учакларда мәетнең җәсәде сәгать ярым эчендә көл булачагы хәбәр ителде.

Закон ляихәсендә бәян ителгәннәргә күрә, әгәр дә крематорияләрдә мәетләрне яндыру тәртибе кабул ителсә, мәетләрне яндыру гомуми һәм мәҗбүри булмаячак, имеш. Бәлки мәетнең дине каршы килмәсә, тере чагында мәетнең ризалык биргән булуы расланса, ул чакта крематорияләрдә мәетнең җәсәде көлгә әйләндерелә. Мәетнең көлләре “урна” эченә, кавануз[114] эченә куелып, вәлиләренә бирелә. Яки кулумбариядә[115] дәфен кыйлына.

Хөкүмәт тарафыннан Дәүләт думасына бирелгән гаять мөһим бу закон ляихәсе мөнәсәбәте белән, ислам фраксиясе[116] миңа мөрәҗәгать итте. Җавап йөзеннән мин бу мәкаләмне яздым.

[111] *Дахилия нәзарәте* — Эчке эшләр министрлыгы.

[112] Биредә сүз 1912 елның ноябрь аеннан 1917 елның февраль аена кадәр эшләп килгән IV Чакырылыш Дәүләт думасы турында бара.

[113] *ляихә* (гарәп.) — проект.

[114] *кавануз* (юнан теленнән алынма; госманлыча: قوانوز) — эченә азык-төлек, дару һәм төрле матдәләр салына торган, авызы киң, озынча итеп ясалган төрле зурлыктагы капкачлы пыяла савытлар.

[115] *кулумбария* (лат.: *columbarium*) — каванузлар сакланыла торган махсус корылма. Мәсәлән, Мәскәү кирмәне диварының Кызыл мәйданга карап торган өлеше колумбарий вазыйфасын үти.

[116] *ислам фраксиясе* — биредә IV Чакырылыш Дәүләт думасының эшендә катнашкан 6 мөселман депутат күздә тотыла.

Кабер кешенең соңгы ватаныдыр, мөкаддәс йортыдыр. Кабер кешенең мәркадедер[117], ятагыдыр.

Коръән кәримнең مَنْ بَعَثَنَا مِن مَّرْقَدِنَا[118], дигән айәт кәримәсенә күрә, кеше шул ятакта сау җәсәде белән [вакытына кадәр] йоклап ята.

Кодрәт кулы белән һәр ягы җиренә җиткерелгән гәүдәне ясалма юл белән җимерү килешми дә, болай итүнең файдасы да юк.

*Муса Җаруллаһ*
*Апрель 10 да, 1913 ел.*
Тип. М-А. Максутова, СПБ. Басков пер., д. 34.

[117] *мәркад* (гарәп.) — түшәк; йокы урыны.

[118] “…***безне ятагыбыздан кем терелтте?***” (Коръән, 36: 52).

# Төшенчәләрнең кыскача сүзлеге

***Әмире-л-мөэминин*** — Мөэминнәрнең әмире, ягъни хәлифә.

*әсхаб кирам* (гарәп.) — хөрмәтле сәхабәләр, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ чакыруына ул үзе исән чакта иярген, аны күргән, аның белән аралашкан кешеләр һәм беренче буын мөселманнар.

*әһл-е ислам* (гарәп.) — ислам динен тотучылар; мөселманнар.

*бәгъде-л-мәүт* (гарәп.) — үлемнән соң; үлемнән соңгы.

*бәрабәр* (фарс.) — бергә, бергәләп, бергәлектә.

*бәрадәр* (фарс.) — ир туган, ир кардәш; абый; эне.

*би-л-иҗмагъ* (гарәп.) — *иҗмагъ белән,* ягъни: дин галимнәренең уртак фикере, уртак карары нигезендә.

*ваҗиб* (гарәп.) — фикъһы (ислами хокук белеме) төшенчәсе — шәригать тарафыннан эшләнергә тиешле гыйбадәт яки гамәлне белдерә; кайбер мәзһәбләрдә фарызга тиң булган нәрсә хөкемендә йөри; мәзһәбенә күрә ваҗибне үтәмәгән мөселман ислам диненнән ваз кичүче (мөртәт) буларак танылмый, ә фарызны инкяр итсә — ислам диненнән чыгарыла.

*вәхшәт* (гарәп.) — кыргыйлык; мәдәниятсезлек.

*вөҗүб* (гарәп.) — *ваҗиб*нең күплек шәкеле.

*газамат* (гарәп.) — бөеклек, олуглык.

*газамат илаһия* (гарәп.) — бердәнбер илаһ булган Аллаһка гына хас олуглык, бөеклек.

*Гаср-ы рисаләт* — Рисаләт (расүллек) гасыры, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ үзенең пәйгамбәрлек вазыйфаларын башкарган дәвер.

*гомран* (гарәп.) — эшкәртелгәнлек; төзеклек; кеше кулы белән, хезмәте белән корылган мохит.

*гонсыр* (гарәп.) — нинди дә булса матди җисемнең аерылгысыз өлеше; матди галәмнең элементлары; нәрсәнең дә булса табигате, асыл сыйфаты.

*Дахилия нәзарәте* — Эчке эшләр министрлыгы.

*дәргяһ* (фарс.) — ишек алды.

*дәфгый сурәттә* — кисәк кенә, көтелмәгәндә; торган җирендә егылып.

*дәфен кыйлу* — җәсәдне җирдә казылган кабергә салып күмү; җирләү.

*дәһшәт* (гарәп.) — куркыныч; тетрәнү.

*җәсәд* (гарәп.) — үлгән кешенең гәүдәсе.

*зарурәт* (гарәп.) — чарасызлык, ирексезлек; мәҗбүр булу.

*зирагъ* (гарәп.) — терсәк; ара (озынлык) үлчәме буларак 0.66 м. тәшкил итә.

*иҗмагъ* (гарәп.) — шәригать хөкемнәрен булдыру алымнарының берсе: дин галимнәренең бердәм төстә яки күпчелегенең нинди дә булса бер шәргый (шәригатькә кагылышлы) мәсьәләне чишкәндә уртак фикергә килүләре, уртак бер карарга килеп үзара ризалашулары.

*иҗмагъ итәргә* (гарәп.) — уртак фикергә, уртак карарга килергә;

*иҗтиһад* (гарәп.) — тырышлык; эшне җиренә җиткереп башкару; дини гыйлемгә ия булган галимнең фикъһы (хокук), яки илаһият белеме (теология) өлкәләрендә тикшеренү нәтиҗәсендә нинди дә булса карарга, хөкемгә килүе.

*икрам илаһи* (гарәп.) — Аллаһ тарафыннан күрсәтелгән хөрмәт, ихтирам, кадерләү.

*инсан* (гарәп.) — кеше; адәм баласы.

*интизамлы* (гарәп.) — тәртипкә салынган, кагыйдәләргә туры килгән.

*кавануз* (юнан теленнән алынма; госманлыча: قوانوز) — эченә азык-төлек, дару һәм төрле матдәләр салына торган, авызы киң, озынча итеп ясалган төрле зурлыктагы капкачлы пыяла савытлар.

*катыйфә* (гарәп.) — бәрхет тукыма.

*кашка* — корбан итеп чалыначак малга сугылган тамга.

*кәлисә* (гарәп.) — чиркәү.

*кулумбария* (лат.: *columbarium*) — каванузлар сакланала торган махсус корылма.

*кяфур* (гарәп.) — кяфур (кайбер исле үсемлекләрдән җитештерелә торган татлы исле матдә; хуш исле май, хушбуй; (камфора).

*лашә* (фарсычадан) — үле гәүдә; үләксә.

*лубан* (гарәп.) — кайбер диннәрдә дини йолалар үткәргәндә исле төтен тарату өчен ягыла торган махсус сагыз; (ладан).

*ляихә* (гарәп.) — проект.

*манзара* (гарәп.) — күренеш.

*мәгъбүд* (гарәп.) — үзенә гыйбадәт ителә торган нәрсә. Мәсәлән, ислам динендә мәгъбүд — Аллаһ, кайбер халыкларда мәгъбүд Кояш булган, һинд динендә мәгъбүд булып исәбе-хисабы булмаган илаһлар торалар.

*мәгъмүр* (гарәп.) — кешеләр яши торган урын; кеше кулы белән төзек хәлгә китерелгән.

*мәетнең вәлиләре* — вафат булган кешенең туган-тумачасы, дус-ише, яки аны җирләү өчен җаваплы булган кешеләр, аның вәкилләре.

*мәзаһиб исламия* (гарәп.) — ислам шәригате кануннары белән эш итә торган белемнең (фикъһы һәм фикъһының ысуллары/методологиясе) мәзһәбләре (юнәлешләре): хәнәфи мәзһәбе, шәфигый мәзһәбе, мәлики мәзһәбе, хәнбәли мәзһәбе.

*Мәккә хәрәмнәре* — Мәккәдә хаҗ йоласы үтәлә торган изге урыннар; *хәрәм* җирлеге Мәккә әйләнәсендәге микатларны (хаҗ һәм гомрә кыйлырга килүчеләрнең ихрам хәленә керергә тиешле булган чикләрне) кичкәннән соң башлана.

*мәлик* (гарәп.) — патша.

***Мәсҗид нәбәви*** — Мәдинә шәһәрендә урнашкан Пәйгамбәр мәчете.

*мәрасим* (гарәп.) — рәсмиләштерелгән йола; нинди дә булса рәсми вакыйганы (исем кушу, туй, җеназа һ. б. ш.) үткәрү, башкарып чыгу тәртибе.

*мәркад* (гарәп.) — түшәк; йокы урыны.

*мәслихәт* (гарәп.) — яхшылык, файда.

*мәшругъ* (гарәп.) — шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән нәрсә яки эш.

*моктасыйд* (гарәп.) — булганны саклап тотучы; юкка сарыф итмәүче.

*мөхәддис* (гарәп.) — Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ хәдисләрен, аларның тапшырылу юлларын (иснадларын) өйрәнүче, хәдис җыентыкларын төзүче дин галиме.

*милли* (гарәп.) — теге яки бу халыкныкы.

*мөкаддәс* (гарәп.) — изге.

*мөстәхәб* (гарәп.) — хупланыла торган; мактаулы.

*нисбәт кыйлырга* — бәйләнешле итәргә; каратырга; кайтарып калдырырга; тоташтырырга.

*ригая итәргә* — кайгыртырга; үтәргә; нинди дә булса эшне җиренә җиткереп башкарып чыгарга.

*саганак эчендә* — коеп яуган яңгыр астында.

*садә* (фарс.) — саф; гади; катлаулы булмаган.

*садәт хәнәфия* — имам Әбу Хәнифә (699–767) исемен йөртүче фикъһы мәзһәбенең атаклы галимнәре.

*садәт хәнбәлия* — имам Әхмәд ибне Хәнбәл (780–855) исемен йөртүче фикъһы мәзһәбенең атаклы галимнәре.

*сәнагать* (гарәп.) — ясалыш; төзелеш.

*Сәййид әл-вөҗүд* (Барлыкның әфәндесе) — Мөхәммәд пәйгамбәрне ﷺ олылау гыйбарәсе.

*сәхабә* (гарәп.) — Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ иярчене, аны үз күзләре белән күргән, аралашкан беренче буын мөселманнардан бере.

*сәхәр вакыты* — төннең таң атар алдындагы вакыты.

*сөктә* (гарәп.) — өянәк.

*сөннәт* (гарәп.) — гадәт; теге яки бу җәмгыятьтә һәркем тарафыннан кабул ителгән эш яки эш тәртибе.

*сөннәт хәсәнә* (гарәп.) — күркәм гадәт; матур гадәт.

*таһир* (гарәп.) — саф, ару, чиста.

*тәгълим* (гарәп.) — өйрәтү; гыйлем бирү, гыйлемләндерү.

*тәрәккъый* (гарәп.) — кешеләр яшәешенең уңай якка үсеш-үзгәреше; прогресс.

*фәкыйһ* (гарәп.) — шәригать хөкемнәре белгече, шәригать кануннарын булдыручы дин галиме.

*фитрый* (гарәп.) — кешегә тумыштан ук хас булган сыйфатлар, мәсәлән, Аллаһка тартылу, гаделлекне гаделсезлектән аера белү һ. б. ш.

*хадисәләр* (гарәп.) — хәлләр, процесслар.

*халәкать* — Аллаһ тарафыннан барлыкның булдырылышы, барлыкка китерелүе.

*хәражҳат* (гарәп.) — чыгымнар.

*хикмәт илаһия* (гарәп.) — Аллаһка гына хас булган тирән һәм һәрьяклап тулы булган белем.

*һидаять* (гарәп.) — дөрес юлга чыгару; дөрес юлны күрсәтү; дөрес юлдан алып барылу.

***Шаригъ хәким*** — Хикмәт иясе булган шәригатьче, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәрﷺ.

“*шәһид-е инсаният*” (гарәп./фарс.) — кешелек дөньясының беренче шәһите, ягъни Аллаһка, Ул биргән иманга тугры калу йөзеннән, аларга хыянәт итмәү йөзеннән үлемгә дучар ителгән беренче кеше.



«Россиядә ислам фикере:
яңарыш һәм яңача карашлар» сериясеннән

*Муса Җаруллаһ Бигиев мирасы*



## *«Муса Җаруллаһ Бигиев мирасы»*

*сериясенә түбәндәге китаплар керә*[1]:

*1* **Русия мөселманнары берлегенең программасы** (СПб., 1906).

*2* **1906 сәнә 16–21 августта җыелган Русия мөселманнары корылтае** (Казан, 1906).

*3* **Русия мөселманнарының өченче корылтае** (Казан, 1906).

*4* **Русия мөселманнары өченче корылтаеның забыт җәридәләре (протоколлары)** (Казан, 1906).

*5* **Нижний Новгородта булып узган Русия мөселманнары өченче корылтаеның карарлары (16–21 август, 1906)** (Казан, 1906).

*6* **Коръән укылышлары һәм кыйраәт тарихы** (Казан, 1907).

*7* **“Әл-Лөзүмийәт”не язган фәйләсүф имам Әбу әл-Галә Әхмәд бине Габдулла әл-Мәгарри хәзрәтләренең тәрҗемә-и хәле** (Казан, 1907).

---

[1] Китап «Россиядә ислам фикере: яңарыш һәм яңача карашлар» сериясе кысаларында «Медина» Нәшрият йортында басмага әзерләнә.

8 **Олуг фәлсәфәче имам Әбу әл-Галә әл-Мәгарри хәзрәтләренең “Әл-Лөзүмийәт” дип аталган бөек әсәреннән сайлап алынган тәрҗемәләр** (Казан, 1907).

9 **Гарәп телендә әдәбият һәм ислам голүмнәре** (Казан, 1907).

10 **Мәвараэннәһергә сәяхәт** (Казан, 1908).

11 **Шәригать ни өчен роэятне сайлаган?** (Казан, 1909).

12 **Коръән сүзләренең язылышын дөресләү** (Казан, 1909).

13 **“Әл-Мөвафәкать”нең нәшер ителүенә кагылышлы бер ике сүз** (Казан, 1909).

14 **Кавагыйд фикъһия: ислам хокукының кагыйдәләре** (Казан, 1910).

15 **Диваны Хафиз: Хафиз Ширази шигырьләренең тәрҗемәсе** (Казан, 1910).

16 **Илаһи мәрхәмәтнең дәлилләре** (Оренбург, 1911).

17 **Кешеләрнең илаһка инануларына бер караш** (Оренбург, 1911).

18 **Озын көннәрдә ураза** (Казан, 1911).

19 **Сионизм: йәһүдләрнең яшәеш фәлсәфәсе** (Оренбург, 1911).

20 **Халык игътибарына берничә мәсьәлә** (Казан, 1912).

21 **Исламийәттә кадер** (Казан, 1912).

22 **Маидә (Аш-су)** (СПб., 1914).

23 **Зур мәсьәләләр хакында вак фикерләр** (СПб., 1914).

24 **Мәет яндыру мәсьәләсе Дәүләт думасында** (СПб., 1914).

25 **Мөляхазә: Риза Фәхретдин әсәренә күзәтү** (Петроград, 1914).

26 **Ислах итүнең нигезләре** (Петроград, 1915).

27 **Асыл хокуклар (124 статья). 1906 нчы ел, апрель 23тә расланган төп кануннар** (Петроград, 1916).

28 **Зәкят** (Петроград, 1916).

29 **Шәригать нигезләре** (Петроград, 1917).

30 **Гаилә мәсьәләләре** (Петроград, 1918).

31 **Ислам милләтләрендә дини, әхлакый, иҗтимагый, сәяси мәсьәләләр һәм чаралар хакында** (Берлин, 1923).

32 **Мөскират: ислам шәригатендә исерткеч мәсьәләләре** (Истанбул, 1927).

33 **Төркия бөек милләт мәҗлесенә мөрәҗәгать** (Каһирә, 1931)

34 **Коръән кәрим айәт кәримәләренең могъҗизави гыйбарәләренә күрә Йәэҗүҗ** (Берлин, 1933).

35 **Коръән кәрим айәт кәримәләренең нурлары яктысында ханым** (Берлин, 1933).

36 **Тарихның онытылган сәхифәләре** (Берлин, 1933).

37 **Коръән Кәрим айәт кәримәләренең могъҗизави гыйбарәләрендә сәмиләрнең әнбияләре, сәмави китаплары** (Берлин, 1933).

*Искәрмәләр өчен*

Искәрмәләр өчен

*Искәрмәләр өчен*

## *Искәрмәләр өчен*

www.idmedina.ru

Муса Җаруллаһ Бигиев

# МӘЕТ ЯНДЫРУ МӘСЬӘЛӘСЕ ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНДА

*Муса Җаруллаһ Бигиевның 150 еллыгына (1875–1949)*

«Россиядә ислам фикере:
яңарыш һәм яңача карашлар»
*Муса Җаруллаһ Бигиев мирасы*

Гомуми мөхәррире: илаһийәт докторы, СПбГУ профессоры Дамир Мухетдинов
Госманлы татар теленнән тәрҗемә һәм искәрмәләр: А. Г. Хәйретдинов
Сериянең җаваплы мөхәррирләре: Айдар Хәйретдинов, Ренат Ислямов
Серияне матбугатка әзерләү өчен җаваплы мөхәррирләр:
Гөлфия Хабибуллина, Руслан Баишев
Бастырып чыгару өчен җаваплы: Сайидмухаммад Абубакаров
Портретлар авторы: *Ләйлә Хасьянова*
Хаттат: Сергей Сорочьев
Корректор: Гөлфия Хабибуллина
Компьютерда биткә салучы: Александр Паньшин
Тышлык бизәлеше: yustudio.ru

Басарга кул куелды: 27.03.2024
Форматы 84×108/32
Офсет басма
Тиражы: 5000 д.

ISBN 978-5-9756-0248-0

ООО “Медина” Нәшрият йорты
109382, Мәскәү, проезд Кирова, 12
Тел./факс: +7 (495) 684-47-04
e-mail: idmedina@yandex.ru

www.dumrf.ru www.muslims.ru www.muslim.ru www.miu.su www.islamsng.com
www.muslim-forum.info www.manuscriptaislamica.ru www.spbu.ru cis.spbu.ru

فرونلرده اوچاقلرده ميتكْ جسدى ساعت ياريم ايچنده كول اولاجق.

زاقون لائحه سنكْ ملاحظه سنه كوره، اگرده فرهماتوريه‌لرده ميتلرى ياقمق نظامى قبول قيلنور ايسه، ميتلرى ياقمق عمومى مجبورى اولماز. بلكه ميتكْ دينى مساعده ايدر ايسه، حال حياتنده ميتكْ رضاسى ثابت اولور ايسه، او وقت فرهماتوريه‌ده ميتكْ جسدى كول قيلنور. ميتكْ كوللرى «اورنا» ايچنه، قوانوز ايچنه قويولوب، ولي‌لرينه‌ويرلور. ياخود قالومباريه‌ده دفن‌قيلنور.

حكومت طرفندن دولت دوماسنه ويرلمش غايت مهم شو زاقون لائحه‌سى مناسبتيله، اسلام فراكسيه‌سى بكامراجعت‌قيلدى. جواب‌اولمق‌اوزره‌بن‌شو مقاله‌مى‌يازدم.

قبر انسانكْ صوكْ وطنيدر، مقدس خانه‌سيدر.
قبر انسانكْ مرقديدر، ياتاغيدر.

«من بعثنا من مرقدنا.» انسان ياتاق‌ده صاغ جسديله اويور.

قدرت اليله تسويه قيلنمش بنيه‌يى صناعى طريقله هدم ايتمك مناسب دگلدر، فائده‌سى يوقدر.

آپريل ١٠ ده ١٩١٤ سنه.

Тип. М-А. Максутова, СПБ. Басковъ пере. д. 34.

قبرلڭ دورى تمام اولور. او قبرده ديگر بر انسانى دفن ايتمك، قبرستانى ديگر مقصدلره صرف ايتمك جائزاولور.

قبرلك قبرستانلق دورينڭ مقدارى قران كريم‌ده يوز سنه‌در .

فاماته الله مائة عام، ثم بعثه . » (سورةالبقره)

يعنى يوز سنه دن صوڭ يرده اولگى قبرڭ اثرى قالماز . اوراده ديگر بر انسان دفن قيلنه بيلور . قبرستان يوز سنه دن صوڭ ، ديگر مقصدلره صرف قيلنه بيلور .

مدينه ده مسجد نبوى اسكى قبرستان اوزرينه تأسيس قيلندى .

قبرستانڭ ده بر دورى بر مدتى وار ايسه ، قبرستانلق مؤبد دگل ايسه، كله‌جك عصرلر ده قبرستانلرڭ كوبلگى سببيله ير قحطلغندن قورقمق طوغرى اولماز.

قبرستانلر حقنده، ميتلرڭ جسدلرينى قره‌ما توريه‌لرده (گلخانلرده) ياقمق خصوصنده، داخليه نظارتى طرفندن، ١٩١٣ سنه ايون ٢٧ ده، دولت دوماسنه بويوك قطعه‌ده آلتمش صحيفه‌لك ، ٨٠٢ نچى نومر زاقون لائحه سى ويرلمش ايدى .

آلتمش صحيفه‌لك زاقون لائحه‌سنده دفنڭ ضررلرى مشقتلرى، قره‌ماتوريه‌لرڭ فائده لرى آسانلقلرى تفصيل قيلنمشدر .

قره ماتوريه، توركچه تعبير ايدر ايسه‌ك: گلخان ـ ميتلرڭ جسدلرينى ياقمق ايچون مخصوص ياصالاجق بويوك بنادر . حرارتلرى ٨٥٠ درجه اولاجق بويوك

صوكڭ، سحر وقتنده دفن قيلندى. جنازه نبويه تقريبا قرق ساعت منتظر قالمش اولور.

بر آدم دفعی صورتده، ياخود سكته كبی بر مرضله وفات اولور ايسه، بركون، ايكی كون؛ لازم اولور ايسه اوچ كون انتظار ايتمك،كتب فقهيه‌لرك بياننه كوره، واجبدر.

هر حالده، تعجيل، انتظار مسئله‌سی احوالڭ اختلافيله مختلف اولور. موت علامتلری قطعی صورتده ظاهر اولور ايسه، ياخود ساری خسته‌لكلرك بريله وفات اولسه؛ يا ايسه، ميتڭ خانه‌ده حضوری خانه خلقنه طارلق قيلسه، ضرر ويرسه، البته شو صورتلرده تعجيل واجب اولور. موت مشتبه اولور ايسه، موتڭ تحققنه قدر انتظار واجب اولور. لكن انتظار خانه اهلنه طارلق ويرور ايسه او وقت ميت ديگر يره نقل قيلنور.

معقول بر غرض، معتبر برسبب بولنور ايسه، ميتلری قبردن چيقارمق، بر يردن ديگر يره، بر قبردن ديگر قبرستانه نقل ايتمك مشروعدر. عصر رسالتده بر نيچه دفعه بويله حاللر واقع اولدی. امير المؤمنين خليفه علی حضرتلرينی اوغلی حسين عليه السلام حضرتلری اولگی قبرندن چيقاروب، كوفه‌ده قصر الاماره‌ده دفن ايتدی.

قبرستانده قبرله قبر آراسی تقريبا ايكی ذراع قدر قيلنور. يرڭ تحملندن زياده ميتلری دفن ايتمك مقبول دگلدر.

قبرده قبرلك، قبرستان ده قبرستانلق مدتی يرڭ اقليمڭ اختلافيله مختلف اولور. جسد قبرده تمام چوروب، نه وقت تمام طوپراق اولور ايسه، او وقت قبرڭ مدتی

على العا ده كفن فرض ايسه ده، قيمتلى شيلرى ميتنڭ قبرينه تلف ايتمك مطلوب دگلدر. درست، سيدالوجود شارع كبير عليه الصلاة والسلام حضرتلرينڭ مقدس قبرلرى آق قطيفه ايله توشه‌لدى. لكن اصحاب كرامڭ آرزوسيله دگل ايدى؛ بلكه يالڭز نبى محترمڭ خادمى شقرانڭ همتيله اولمش ايدى.

جسدلرى قبرلره تابوتلرده وضع ايتمك شارع كبير عليه الصلاة والسلام حضرتلرندن‌ده اصحاب كرامدن‌ده منقول اولمامش ايسه‌ده، تابوتلرده دفن ايتمك مشروعدر.

قبرڭ قبله‌سى جهتنده لحد ياصامق ممكن اولور ايسه، انسانڭ جسدينه احترام ملاحظه‌سيله، لحد ياصامق أفضلدر. قوملق يومشاقلق سببيله، ممكن اولماز ايسه، لحدسز براقمق درست اولور.

انسانڭ موتى قطعى صورت‌ده محقق اولور ايسه، جنازه‌يى تعجيل مستحب اولور. ميتى خانه ده اوزاق طوتمق وليلرينڭ كوڭللرينه آغر اولمق احتماالنه كوره. — شارع حكيم عليه الصلاة والسلام حضرتلرى بويورمش:

«عجلوا بالميت. وانه لا ينبغى لجيفة مسلم ان تحبس بين ظهرانى اهله».

لكن بر سبب بولنور ايسه، انتظار جائز، بلكه واجب اولور.

شارع كبير نبى محترم عليه‌الصلاة والسلام حضرتلرى دوشنبه كون، ايرته ساعت سكز طوقز راده‌لرنده وفات اولدى. سه‌شنبه كون، چهارشنبه كيچه‌سنده، تون اورتاسندن

ایرشمه‌مك شرطیله، تیره‌نلگی زیاده ایتمك جائزدر.
لکن انسانڭ جسدینی یر صولرینه قدر ایندرمك کتب
فقهیه ده، نه‌دنلر، منع قیلنمش.

چورومش جسدڭ رائحه‌سی چیغه بیلور قدر قبرلری
صای ایتمك ممنوعدر. یر اوزرنده صاغاناق ایچنده
میتلری دفن ایتمك قطعی صورتده حرامدر.

«عن علی بعثنی رسول‌الله صلی‌الله علیه وسلم ان
لا تدع تمثالا الاطمسته، ولا قبرا مشرفا الا سویته».

شو حدیث سنت قطعیه اولمق اوزره کتب حدیثده
روایت قیلنمشدر. نه قدر قطعی ایسه‌ده نه قدر معقول
بر فرمان نبوی ایسه‌ده، بوتون عالم اسلامیتده هر یرده
هر زمان شدتله اهمال قیلنمشدر. تورکستان، هندوستان
مصر، تورکیا، استانبول شو بویوك بلیه شوملغیله خرابات
اولدی!

شهر ایچنده قریه ایچنده میتلری دفن ایتمك ممنوعدر.
مسجد ایچنه قبر، یاخود قبر اوزرینه مسجد بنا ایتمك
شدتله نهی قیلنمشدر. کلیسه‌لرده اسلام نمازینی اوقومق
جائز اولا بیلور ایسه‌ده، قبر اوزرینه بنا قیلنمش مسجدده
نماز اوقومق فقیهلرڭ بیانلرینه کوره جائز دگلدر.

ضرورت ساعتلرنده بر نیچه میتی مشترك بر قبرده
دفن ایتمك مشروع ایسه‌ده، عادی حاللرده هر انسانڭ
اوزینه مخصوص قبری بولنمق لازمدر. عمومی قبرستانده
بر قبر هر انسانڭ حقیدر. قبرڭ اوزونلغی البته هر
انسانڭ اوز بوینه مناسب اولوب، کیڭلگی نصف
اولاچقدر.

بر سنت حسنه‌در . عقلنه قلبنه استیلا ایدن مقدس بر قوتنڭ فرمانی بولنمادقچه، یاخود آتش ده بویوك بر قدسیت اعتقاد قیلمادقچه، انسان قارندشنڭ جسدینی آتشه آتماز.

۲) دفن هر یرده هر وقت ممکن، الڭ اوچوز خراجتی آز، منظره‌سنده دهشت یوق، منفوریت یوق آسان، گوزل سنت قدیمه در.

درست، شو کونگی مدنیتڭ تکلفلی مراسمیله دفن ایتمك غایت آغردر. مصارف غایت کوب اولور. لکن گناه دفن‌ده دگل؛ بلکه بیهوده مراسم‌ده‌در. ساده اصول اوزرنده دفنڭ خراجتی آز اولور. دفنڭ مراسمی ساده‌لشدرلسه، آغرلق قالماز.

٤) قبرلر هم قبرستان حقنده لازم شروطلر تمامی رعایه قیلنور ایسه، شهرلر قریه‌لر ایچون قبرستانڭ ضرری بولنماز.

قبرستانلری شهردن قریه‌دن ایگونلك یراردن باقچه‌لردن قویولردن صو یوللرندن اوزاق یرده، چیت ده صحرا ده قیلمق تیوشدر. قبرستان ده قوریلق شرطدر. صازلق یری قبرستان یاصامق، فقیهلرڭ بیانلرینه کوره، موافق دگلدر.

یرڭ حالنه کوره، قبرلری تیره‌ن (عمیق) قیلمق تیوشدر. اهل حدیثڭ روایتنه کوره، شارع حکیم علیه الصلاة والسلام حضرتلری بویورمش:

«احفروا واوسعوا واعمقوا».

محدثلرڭ فقیهلرڭ بیانلرینه کوره، قبرڭ تیره‌نلگی علی‌العاده ایکی ذراع اولور. یر ایچنده منبع صولرینه

«بنية الانسان فی مماته کبنیته فی حیاته. کسر عظم المیت مثل کسر عظم الحی.»

شو جامع حدیثی ابو داود، ابن ماجه کبی بویوك امامار روایت ایدوب، ابن ماجه حضرتلری «فی الاثم» سوزینیده زیاده ایتمش. شارع حکیمك شو کلمه جامعه سی فقیهلرك اجتهادلرینه اساس اولدی. بوکا کوره، میتك جسدینی یاقمق بوتون فقیهلر نظرنده بالاجماع ممنوعدر. میتك بعض اعضالرینی صندرمق قطع ایتمك، قصاص هم ضمان لازم اولماسه ده، بالاجماع ممنوعدر.

قارننده آلتی آیلق بالاسی وار بر خاتون، دیه لم، وفات اولدی؛ یاخود قتل قیلندی. بالاده حرکت کبی جان اثری ظاهردر. شو مسئله ده فقیهلرك نظری اختلاف ایتمش: سادات حنفیه نظرنده، قارن یاروب، جنینی چیقارمق لازم اولور. چونکه جنینك موتنه سبب اولاچق بدننك حرمتی ساقطدر. سادات حنبلیه نظرنده قارن یارمق حرامدر. چونکه جنینك موهوم حیاتی ایچون خاتونك متقین محقق حرمتی فدا قیلنه ماز. ایکی نظرك برینی ترجیح قصد یله دکل، بلکه انسانك حرمتنه فقهیلرك نظرلرینی کوسترمك داعیه سیله شو مسئله یی بوراده نقل ایتدم.

قدرت الیاه طبیعی کبی الك بویوك رسامك معرفتیله مهارتیله بنا قیلنمش مقدس هیکلی، محترم بنیه یی صناعی طریقیله تلف ایتمك موافق اولماز؛ بلکه طبیعتك اوز تصرفنه تسلیم ایتمك دها کوزل اولور.

٢) دفن انسانلرك احوال روحیه لرینه الك موافق؛ میت ولیلرینك خاطرلرینه مقبولیت جهتیله ده الك مناسب

حيوانلرده بويوك خطر اولاچقدر . اويله ايسه، ميتلرى ياقمق اڭ آسان اڭ گوزل تدبير اولور .

فيلسوف اسلام ابو العلا حضرتلرى اللزوميات‌ده ديمش:

غـل المليك بلاده من اهلها — بالماء اذ جاؤا بسوء شنار
ويقال ان الله جل ثناؤه — يوما يطهر ارضه بالنار

يعنى: انسانلرڭ پيسلكلرندن يريوزينى طوفان صولريله يركڭ مليكى بر وقت ياىقامش ايدى . بر وقت كلور ، انسانلرڭ لاشه‌لرندن ير يوزينى آتشله پاكلمك حاجت اولور .

فيلسوفڭ او وقتى بعض مملكتلره نسبتله اشته شو كون ايندى كلمش اولسه كرك .

ميتلرى ياقمق لهنه يوقارى‌ده سويلنمش ملاحظه‌لر، ديه‌لم ، طوغريدر . لكن ميتلرڭ جسدلرينى قبرلره دفن ايتمك ادبلرى حقنده اسلاميتڭ ملاحظه‌لرى دها زياده طوغريدر، دها زياده عاليدر .

١) خلقتڭ عجيب صنعتنه ، انسانڭ محترم بنيه‌سنه احترام وظيفه‌سى دفن‌ده دها زياده در . حال حيات ده انسانڭ بنيه‌سى محترم ايدى . موت او حرمتى ازاله ايتمز . حرمت حقوق ذاتيه‌دندر؛ فقيهلرڭ عرفيله تعبير ايدر ايسه‌ك ، حرمت حقوق الهيه‌دندر . حتى انسانڭ اوزى ده اوزينڭ بنيه‌سنه تعدى ايده بيلمك حقندن محرومدر . اوزينڭ جسدينى بعد الموت ياقمق حقنده بر انسان حال حياتنده وصيت ايدر ايسه‌ده، وصيتى تنفيذ قيلنماز . حقوق مقدسه خلافنه وصيت عموميتله هر وقت باطل اولور .

ام المومنين سيده عائشه، ام المومنين سيده ام سلمه حضرتلرى روايت ايتمش:

انسان فکرینی نظرینی بر مسئله ده جهتلرك بعضلرینه قصر ایدر ایسه، میت یاقمق کبی دینی ادبلری بلکه استحسان ایده بیلور. فیلسوف اسلام ابو العلا حضرتلری اللزومیات ده دیمش :

فاعجب لتحریق اهل الهند میتهم — وذاك اروح من طول التباریح
ان حرقوه فما یخشون من ضبع — تری الیه ولا خفی وتطریح
والنار اطیب من کافور میتنا — غبا واذهب للنکراء والریح

یعنی: میتلری یاقمق دها گوزلدر. دون کبی اوزون اوزون زحمتلری، بویوك خراجتلری یوقدر، خطری ده یوقدر. اوت بزم میتلرك کافورلرندن عاقبت جهتیله دها زیاده پاکدر؛ یر یوزندن چورك لاشهلری، آغر ایسلری آز وقت ایچنده ازاله ایدر.

هر انسانك فکرینه، هر ملتك دینی ادبلرینه احترام کوزیله نظر ایدر ایسهك، بویله سوزلری جریتله سویلهمك البته جائز اولور.

مسئلهیی کلهجك عصرلر، یاخود شو عصرده بعض یرلر اعتباریله ملاحظه ایدر ایسهك، او تقدیرده میتلری یاقمق دائده سنه قوتلی دلیللر بولنمق ممکندر: یر یوزنده عمران، مدنیت ترقی ایتدکچه، سنه دن سنهیه عصردن عصره انسانلرك نفوسی همان همان البته آرتاچقدر. معمور مرکزلرك جوارنده کفایه قیلور قدر یر بولمق غایت آغر اولاجقدر. میتلرك کوبلگی، یرلرك طارلغی قبرستانلرك اوزاقلغی، خراجتك چوقلغی حسبیله دون ایتمك غایت مشکل اولاچقدر. قبرستان طولوب بتدکدن صوکره ده دفن همان دوام ایدر ایسه، او وقت قبرستانك عفونتی، فاسد مادهلرك هوا ده انتشاری انسانلره ده

بلكه باشقه معامله لرده احتمال بولنمشدر . درست، هندوستان كبى ژاپونيا كبى هم مدنيت هم دياننت دنياسنده ميتلرينڭ جسدلرينى ياقمق عادت دينيه‌سى الڭ قديم زمانلردن باشلانوب شوكونه قدر دوام ايتمشدر.

مدنى متدين او ملتلر مقدس دينلرينڭ فرمانيله، معبودڭ رضاسنه نائل اولمق قصديله، ميتلرينى احترام قيلوب معبودڭ دركاهنه جنتلرينه اوزاتمق اميديله اوله‌سه كرك ميتلرڭ جسدلرينى آتشلره ياقار ايديلر .

فيلسوف اسلام ابو العلا حضرتلرى اللزوميات‌ده ديمش :

اولائك يحرقون الميت نسكا ويشعره لبانا ملهبوه

يعنى، هندولرده ميت ياقمق نسك ايدى، عبادت ايدى.

اهل اسلام مكه حرملرينه سوق قيلنور هدى قربانلرينى نصل اشعار ايدرلر ايسه ، اللهڭ دركاهنه سوق قيلنه‌جق ميتلرينى هندولرده لبان كبى بخورله اويله اشعار ايدرلر .

اسلام ادبلرينڭ گوزللگى بنم نظرمده بر بينه‌در . اويله ايسه‌ده، ديگر ملتلرڭ دينى ادبلرينه اعتراض ايتمكدن بن صاقنورم .

بوددا مذهبنده ميت ياقمق، اسلاميتده دفن كبى، بر عبادتدر، دينى بر ادبدر . بويله خصوصلرده فيلسوف ابو العلا حضرتلريله برابر :

سيان الباسد ما لان من كفن وطرحه فى لظى النار محتدم

ديه بيلورز. يعنى: يومشاق كفنلره صاروب ميتڭ جسدينى دفن ايتمك، يانوب آلاولانوب طورور آتش ايچنه ميتڭ جسدينى آتمق هر برى برابردر .

اولور . بوڭا كوره، میتڭ جسدینی یومق یایقامق، حالنه مناسب صورتله تكفین تجهیز قیلمق، نعشی حضورنده جنازه نمازی اوقومق، قبرینه قدر جماعتله اوزاتمق، نهایت، قبرده لحد ایچنه دفن ایتمك، احترام ملاحظه‌سیله، فرض اولمشدر .

٢) هوادن یر یوزندن اذالری عفونتلری فاسد ماده‌لری دفع ایتمك اساسی .

جان چیقدقدن صوڭ، معلوم، البته هر حیوانڭ لاشه‌سی بوزولور، ایسله‌نور . ایس هوایی بوزار؛ فاسد ماده‌لرڭ تأثیریله هوا آغولانور . لاشه‌لر اكثریتله ساری مرضلرڭ عنصرلرینی ده هوا‌ده نشر ایدرلر . شو حادثه‌لره مقابل الڭ گوزل الڭ آسان تدبیر ـ یورتلردن، ایگون یرلرندن، باقچه‌لردن چیت یرده صحراده، تیره‌ن چوقورلرده میتلری دفن ایتمكدر .

قبرده میتڭ جسدی آز وقت ایچنده چورر؛ یعنی بنیه‌سنده بولنور بوتون اجزالرینی اصللرینه اعاده ایدر . طبیعت خزینه‌لرینڭ اقتصاد صندوقلرینه بویوك اعانه اولور . انسانلره آغر رائحه‌سیله اذا، منفور منظره سیله دهشت ویرمز . یعنی الڭ آسان بر تدبیر برکه سنده هم احترام وظیفه‌سی، هم حفظ صحت اقتضاسی، هم طبیعتڭ اقتصادی تأمین قیلنمش اولور .

بوڭا كوره، بوتون انسانیت دنیاسنده میتلری قبرلره دفن ایتمك سنت الهیه‌سی عمومیتله قبول قیلنمشدر . الڭ اولگی شهید انسانیت، طبیعتڭ ارشادیله، بوڭا كوره، دفن قیلنمشدر .

یوقاری ده سویله‌دك : طبیعتڭ ارشادی اكثریتله هدایت اولور؛ عاقبت جهتیله هر وقت ضررسز چیقار . درست، وحشت دنیاسنده میتلرینڭ لاشه‌لری حقنده

عطالتده فائـده سز براقماز . جانلی مواليدی حال حياتلرنده تربيه ايدر طبيعت، بعد الموت او مواليدك بنيه‌لرينی تحليل ايدرده ، احتياط صندوقلرنده وقتـنه قدر حفظ ايدر . انسانك حيوانلرك استفاده‌سندن چيقمش بوتون فضلات بوتون لاشه‌لر طبيعت فابريقه‌لرنده غايت قيمتلی خام مال اولور . او مالـلری صناعی طريقلرله تلف ايتمه‌يوب، طبيعت تصرفنه تسليم ايتمك مناسبدر ، ياخود لازمدر .

فيلسوف اسلام ابو العلا حضرتلری اللزوميات‌ده ديمش:

وما الارض الامثنا، الرزق تبتغی فتأكـل من هذا الانام وتشرب.

يعنی: يرده تمام بزم كبيدر، رزق آرار. بوكا كوره، انسانلرك‌ده حيوانلرك‌ده تـنلرينی‌ده قانلرينی‌ده اكل ايدر.

انسانلرك جسدلرينی قبرلرده دفن ايتمك، قران كريمك بيانـنه كوره، بوتون انسانيت دنياسنه نسبتله بر سنت الهيه كبی اولدی ديدك. شو سنت الهيه، دور دائمی جهتيله، طبيعتك مصلحتلرينده موافقدر ديدك .

بوكا كوره، بوتون امت اسلاميه بوتون مذاهب اسلاميه دفنك وجوبنه اجماع ايتدی. ميتلرك جسدلرينی قبرلرده دفن ايتمك بالاجماع فرض اولدی.

دفـنك واجـبلگی بر نيچه اساس اوزرينه مبنيدر:

١) انسانك جسدينه احترام ايتمك اساسی.

شارع حكيم سيد الوجود عليه الصلاة والسلام حضرتلرينك تعليملرينه كوره ، انسانك اوزی‌ده جسدی‌ده، هم حياتده هم مماتده طاهردر، محترمدر . حيوان لاشه‌سی كبی، انسانك جسدينی‌ده دفنسز براقمق، ياخود محترم بنيه‌لرينی آتش‌ده ياقمق، يا ايسه قوش‌قورتلره آتمق انسانك حرمتنه نسبتله تحقير

یعنی: یرلك طیش یوزینی حال حیات ده انسانلرك اوزلرینه، ایچ یوزینی بعد الموت جسدلرینه مسکن قیلمادق می ؟

یر یوزنده، انسانك حال حیات ده سکناسی ، یر ایچنده جسدك بعد الموت قراری ، شو ایکی آیت کریمه ده ، اللهك عظمت الهیه سنه نسبت قیلنمشدر .

حال حیات ده یر یوزنده سکنی انسانك مقدس حقوقیدر . بعد الموت یر ایچنده جسدك قراری ده انسانك مقدس حقی اولور . خانه لرك انسانلره نسبتی نصل ایسه، قبرلرك ده میتلره نسبتی اویله در . خانه سندن انسانی چیقارمق محروم ایتمك ممنوع ایسه جسدینی قبردن محروم ایتمك ده ممنوع اولور .

«انسانلرك جسدلرینی قبرلره دفن ایتمك» سنت الهیه سی طبیعتك مصلحتلرینه ده هر جهتله موافقدر ، بلکه لازمدر . چونکه معادن ، نباتات ، حیوانات دنیا سنه نسبتله کون وفساد ، حیات وممات کبی حالتر وار ایسه ده ، طبیعتك اوزینه نسبتله یالگز دائمی حرکت ، یالگز دائمی دور واردر . طبیعت ده فنا یوقدر ؛ حالدن حاله دونه رماده همان باقیدر ، بلاتوقف دور ایدر . هر بری یردن ناشی نباتات، حیوانات ، عاقبت ، یرك اوزینه البته عودت ایدر . طبیعتك صرفیاتنه بدل ، طبیعت خزینه لرینك وارداتی اولور . حکمت الهیه معرفتیله تقدیر قیلنمش شو توازن برکه سنده طبیعتك حوادثی انتظام اوزرنده دوام ایدر ؛ طبیعت بودجه سنده آچیقلق قالماز . طبیعت غایت مقتصددر ، بر ذره یی ده ضائع ایتمز . طبیعت غایت بویوك مدبردر ، بر ذره یی ده

١) منها خلقناكم وفيها نعيدكم ومنها نخرجكم تارة اخرى.»

يعنى: يردن ياراتدق سزى، يرلك اوزينه قايتارورزده سزى. شو آيت كريمه‌ده، هم ياراتمق هم قايتارمق اللهك عظمت الهيه‌سنه اسناد قيلنمش. يعنى: هم خلق ايتمك، هم دفن ايتمك قانون الهيدر، خلافى جائز اولماز. چونكه قران كريم‌ده اللهك عظمت الهيه‌سنه اسناد قيلنمش شيلره مخالفت ايتمه‌مك ادبى مؤمنلره بويوك بر فريضه‌در.

٢) خلقه فقدره ثم السبيل يسره ثم اماته فاقبره. ثم اذا شاء انشره.

شو دورت آيتك افاده‌سنه كوره، قبرده دفن قيلنمق موت كبى بر سنت الهيه‌در. حكمت الهيه تدبيريله انسانلره موت نصل تقدير قيلنمش ايسه، بعدالموت جسدلرينى قبرلره دفن ايتمك‌ده اكرام الهى اقتضاسيله انسانلره اويله فرض قيلنمشدر.

شو دورت آيت كريمه‌ده اللهك بنده‌لرينه احسانلرى اكراملرى بيان قيلنمشدر: خلق ايتمك، بوتون اعضالرينى تمام قيلوب انسانلره قدرت ويرمك، كمالات يوللرينى هر برينه آسان قيلمق، بعدالموت جسدلرينى قبرلره دفن ايتمك ـ شو شيلرك هر برى انسانلره اللهك احسانيدر، اللهك اكراميدر. آيت كريمه‌ده هم موت هم قبرلره دفن اللهك اوزينه اسناد قيلنوب، موتك طبيعيلگى لازملگى كبى دفنك‌ده طبيعيلگى لازملگى بيان قيلنمشدر..

دفن، شو آيت كريمه‌لرك افاده‌لرينه كوره، بر كرامت الهيه‌در، يعنى اللهك انسانلره بر احترامدر.

٣) الم نجعل الارض كفاتا احياء واموانا.

شو ایکی آیت کریمه‌ده الك اولـکی انسانك الك اولـکی اشلرندن ایکی اشی‌بزه حکایت قیلنمشدر.

١) بری اوزینك برادرینی قتل ایتمك جنایتی.
قرآن کریم ده شو بویوك جنایت انسانك اوزینه انسانك هواسنه اسناد قیلنمق عباره‌سیله اینمشدر.

٢) دیگری برادرینك جسدینی دفن ایتمك فکرینه انسانك اهتداسی.

جنایتلرك الك بویوگنه اقدام ایده بیلمش اولـکی انسان هدایتلرك الك اوفاغنده‌ده عاجز قالمش. یعنی، برادرینی قتل ایده بیلمش، لکن طبیعتدن تعلیم آلمادقچه جسدینی دفن ایده مه‌مش. — قتل ایتمك جنایتی انسانك هواسیله اختیاریله معرفتیله ایدی. دفن ایتمك هدایتی ایسه، طبیعتك ارشادیله غرابك تعلیمیله اولدی.

الك اولـکی «شهید انسانیت» حرمتنه طبیعت طرفندن الك اولـکی انسانلره تعلیم قیلنمش دفن هدایتی برسنت طبیعیه ایدی؛ عاقبت، بوتون انسانلره بر سنت ملیه اولدی.

صحابی ابی بن کعب سیدالوجود علیه‌الصلاة والسلام حضرتلرندن روایت ایتدی:

«الحد لآدم، وغسل بالماء وترا. فقالت الملائکة هذه سنة ولد آدم من بعده.» یعنی: انسانلرك بویوك باباری آدم بر نیچه دفعه غسل قیلنوب، دفن قیلندی. میتلرك جسدلرینی غسل ایدوب دفن‌ایتمك باباری آدمدن صوك بوتون بالالرینده‌ده سنت فطریه سنت ملیه اولدی.

قرآن کریم متعددآیت کریمه‌لرده شو سنت فطریه‌یی تأکید ایتدی، ایجاب ایتدی:

محترم یوسف افندی
آقچورا حضرتلرینه هدیه.
۱۹۱٤ سنه سنه بر برده
پترسبورغ
موسی جار الله.

**موسی جارالله.**

(دولت دوماسنده)

# میت یاقمق مسئله‌سی

میتاری قره ماتوریه ارده
یاغو حقنده حکومت طرفندن
دولت دوماسنه ویرلمش
زاقون لائحه‌سی مناسبتیله.

انسان اوزینڭ هواسیله اوزینڭ معرفتیله اش قیلور ایکن جنایت ایده بیلور ایسه ده، طبیعتڭ ارشادیله حرکت ایدر ایکن اکثریتله اصابت ایدر.

طبیعت یالڭز انسانلری دگل بلکه بوتون حیوانلری ده اوزلرینڭ مصلحتلرینه سوق ایدر. اختیاری اشلر ده فساد بولنه بیلور ایسه ده، طبیعتڭ سوقی، طبیعتڭ ارشادی هر وقت هدایت اولور.

شو حقیقتڭ امین شاهدلری قران کریمده واردر. مثلا: المائده سوره‌سنده، ۳۰ – ۳۱ نچی آیت کریمه‌لرده غایت آچیق بر شاهد انسانلرڭ اعتبارلرینه عرض قیلنمشدر:

«فطوعت له نفسه قتل اخیه فقتله فاصبح من الخاسرین. فبعث الله غرابا یبحث فی الارض لیریه کیف یواری سوأة اخیه قال یاویلتی اعجزت ان اکون مثل هذا الغراب فاواری سوأة اخی فاصبح من النادمین.»

موسى جاراللّٰه

# ميت ياقمق مسئلەسى

## (دولت دوماسنده)

***Факсимиле.*** *Бигиев М.* Мәет яндыру мәсьәләсе (Дәүләт думасында). Санкт-Петербург: Типография М.-А. Максутова, 1914. 16 б.

الإمام الفاضل
موسى جار الله بيگييف



**موسى جار الله بيگييف**

**1949–1875**

«روسیا ده اسلام فکری
یانگرش هم یانگاچه قاراشلر»
سلسله سندن

**موسی جار الله بیگییف میراثی**